Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

# КАРАР № L-1

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 17 феврале

2020-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Социаль-икътисади үсеш Стратегиясен раслау турында

2014 елның 28 июнендәге "Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында" 172-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" №131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасының 2015 елның 17 июнендәге "2030 елга кадәр Татарстан Республикасының Социаль-икътисади үсеш стратегиясен раслау турында" 40-ЗРТ номерлы Законын исәпкә алып, 2019 елның 5 апрелендә Татарстан Республикасының "2030 елга кадәр Татарстан Республикасының Социаль-икътисади үсеш стратегиясен раслау турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 31-ЗРТ номерлы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30 маддәсе нигезендә, ачык тыңлауларның нәтиҗәләрен карап, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.2020-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Социаль-икътисади үсеш Стратегиясен кушымта нигезендә расларга..

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 16 ноябрендәге "2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Социаль-икътисади үсеш стратегиясен раслау турында" XIII-3 номерлы карарын көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының бюджет, финанслар, икътисад, җирле салымнар һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Советының
2020 елның 17 февралендәге
L- 1 номерлы карарына
кушымта

**2020-2021 елларга**

**һәм 2030 елга кадәрге план чорына**

**Татарстан Республикасы**

**Балык Бистәсе муниципаль районының**

**Социаль-икътисади үсеш**

**СТРАТЕГИЯСЕ**

Балык Бистәсе штп., 2020 ел

## ЭЧТӘЛЕК

2020-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Балык Бистәсе муниципаль районының Социаль-икътисади үсеш стратегиясе паспорты ............ .3
1. Гомуми нигезләмәләр.......... 4
2. ББМР Стратегиясенең максатлары һәм бурычлары .......... 6
3. ББМР ның социаль-икътисади хәленә сыйфатлама.......... 6
3.1. Икътисади-географик хәленең төп мәгълүматлары һәм үзенчәлекләре .......... 6
3.2. ББМР ның төп социаль-икътисади күрсәткечләре.......... 8
4. ББМР ның көндәшлек өстенлекләре.......... 11
4.1. Транспорт-логистика инфраструктурасы .......... 11
4.2. Файдалы казылмаларның булуы .......... 12
4.3. Энергетика 12
5. Балык Бистәсе муниципаль районы үсешенең төп юнәлешләре. Проблемалар һәм аларны хәл итү юллары.......... 12
5.1. Икътисадны үстерү .......... 13
5.2. Агросәнәгать комплексын үстерү .......... 14
5.3. Сәнәгатьне үстерү .......... 20
5.4. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү .......... 21
5.5. Туризмны үстерү.......... 23
5.6. Куллану базарын үстерү.......... 25
6. Социаль өлкәне үстерү .......... 26
6.1 Сәламәтлек саклау .......... 26
6.2 Мәгариф.......... 30
6.3 Мәдәният.......... 33
6.4. Спорт.......... 40
6.5. Халыкның мәшгульлеге һәм социаль ярдәм .......... 50
ББМР БК, “Доверие – Ышаныч” халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге (килешү буенча), җирле үзидарә органнары 55
7. Территорияне үстерү.......... 56
7.1. Торак төзелеше һәм территорияләрне төзекләндерү.......... 56
7.2. Торак-коммуналь хуҗалыгы.......... 60
7.3. Юлларны карап тору .......... 66
8. ББМР Стратегиясен тормышка ашыру механизмы .......... 67
9. ББМР Стратегиясен тормышка ашыру чараларының җыелма исемлеге .......... 67
10. ББМР Стратегиясен тормышка ашыруның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү .......... 87

**2020-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Балык Бистәсе муниципаль районының Социаль-икътисади үсеш стратегиясе паспорты**

| | |
|---|---|
| Стратегиянең җаваплы башкаручысы | Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Стратегияне башкаруда катнашучылар | Балык Бистәсе муниципаль районы җирлекләренең җирле үзидарә органнары |
| Стратегиянең максатлары | Район икътисадын үстерү нигезендә Балык Бистәсе муниципаль районы халкының тормыш сыйфатын күтәрү |
| Стратегиянең бурычлары | 1) инвестицияләр җәлеп итү;<br>2) Балык Бистәсе муниципаль районының финанс-икътисади үз-үзен тәэмин итү (үзҗитенкелек) дәрәҗәсен күтәрү;<br>3) туризмны үстерү;<br>4) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру;<br>5) өстәмә эш урыннары булдыру;<br>6) көтелгән гомер озынлыгын арттыру;<br>7) торак пунктларны төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү. |
| Стратегияне тормышка ашыруның төп нәтиҗәләре һәм сроклары | Стратегияне тормышка ашыруның төп нәтиҗәләре булачак:<br>- халыкның тормыш сыйфатын яхшырту;<br>- 2030 елга:<br>• ВТП (ТТП) ны 87% ка арттыру;<br>• яңа җитештерү куәтләрен ачу хисабына бюджетның тәэмин ителеше;<br>• көтелгән гомер озынлыгын 80 яшькә кадәр җиткерү;<br>• 250 яңа эш урыны булдыру; |

| | |
|---|---|
| | • уртача айлык хезмәт хакын 32284 сумга кадәр җиткерү (71)%).<br><br>- 2021 елга:<br>• ВТП (ТТП) ны 34% ка арттыру;<br>• инвестицияләрне 89% ка арттыру;<br>• өстәмә яңа 154 эш урыны булдыру, шул исәптән туризм тармагында;<br>• авыллар, бистә эчендәге юлларны норматив хәленә китерү, халыкны эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итү.<br>Стратегия 2020-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр Балык Бистәсе муниципаль районын үстерү перспективасы белән эшләнде. |
| Стратегияне финанслау | Финанслау күләме ел саен җирле бюджетны формалаштырганда һәм кабул иткәндә тәгаенләнә.<br>Республика бюджеты хисабына финанслау күләме бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштыру этабында тәгаенләнә һәм аңа Татарстан Республикасы бюджетын кабул итү процессында төзәтмәләр кертелә. |

## 1. Гомуми нигезләмәләр

2020-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Балык Бистәсе муниципаль районының Социаль-икътисади үсеш стратегиясе (алга таба – Балык Бистәсе МР Стратегиясе) 2014 елның 28 июнендәге “Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында” 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2015 елның 16 мартындагы “Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында” 12-ЗРТ номерлы Законы һәм 2015 елның 15 мартындагы “2030 елга кадәр Татарстан Республикасының Социаль-икътисади үсеш

стратегиясен раслау турында” 40-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының төп нигезләмәләре нигезендә эшләнде (алга таба – Стратегия 2030).

Балык Бистәсе МР (ББМР) Стратегиясен тормышка ашыруның төп максаты – район икътисадын үстерү нигезендә Балык Бистәсе муниципаль районы халкының тормыш сыйфатын күтәрү.

ББМР Стратегиясен тормышка ашыру чоры югарыда телгә алынган законнар белән бәйле.

ББМР Стратегиясен эшләгәндә һәм тормышка ашырганда Стратегия 2030 тарафыннан билгеләнгән 3, 6 һәм 15 ел диапазоннарында өч еллык үзгәрүчән (өзлексез) планлаштыру методын куллану планлаштырыла.

Шуңа бәйле рәвештә ББМР Стратегиясенең төп чаралары 2020-2021 елларга тупланган.

Ел саен чаралар планын үтәү нәтиҗәләре буенча һәм ББМР үсешенең тышкы һәм эчке факторларыннан чыгып, чираттагы өч еллык план чорына (2017-2019 еллар, 2018-2020 еллар, 2019-2021 еллар) чаралар детальләштерелә.

2021 елда ББМР Стратегиясенең төп этабы тәмамланганнан соң, зарурлык булса, аңа тиешле үзгәрешләр кертеләчәк, шулай ук шул ук өч еллык үзгәрүчән (өзлексез) планлаштыруны файдаланып, чираттагы алты еллык чорга чаралар планы эшләнәчәк.

ББМРның социаль-икътисади үсеш мәсьәләләрен хәл итү үсешкә комачаулый торган проблемалар исемлегенә һәм сәбәп-тикшерү бәйләнешләренә нигезләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары (алга таба – ДХБО) һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының (алга таба – ҖҮО) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең 2016 елның 3 мартындагы X съезды йомгаклары (№ 01-2264) буенча Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов тарафыннан расланган һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры И.Ш.Халиков һәм муниципаль берәмлекләр Советы Президиумы рәисе М.З.Шакиров белән килештерелгән уртак чаралар планы нигезендә ББМР ның авыл җирлекләре ББМР Стратегиясе кысаларында үзләренең

социаль-икътисади планнарын эшлиләр. Аларның үтәлешенә мониторингны ББМР Башкарма комитеты тәэмин итә (алга таба – ББМР БК).

## 2. ББМР Стратегисенең максатлары һәм бурычлары

Балык Бистәсе МР Стратегиясен тормышка ашыруның төп максаты – район икътисадын үстерү нигезендә Балык Бистәсе муниципаль районы халкының тормыш сыйфатын күтәрү.

Тәгъбирләнгән максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителергә тиеш:

инвестицияләр җәлеп итү;

Балык Бистәсе муниципаль районының финанс-икътисади үз-үзен тәэмин итү (үзҗитенкелек) дәрәҗәсен күтәрү;

туризмны үстерү;

кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру;

өстәмә эш урыннары булдыру;

көтелгән гомер озынлыгын арттыру;

торак пунктларны төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү.

## 3. ББМР социаль-икътисади хәленә сыйфатлама

### 3.1.Икътисади-географик хәленең төп мәгълүматлары һәм үзенчәлекләре

ББМР үзәге – Балык Бистәсе штп. – Татарстан Республикасы башкаласына якын урнашкан район үзәкләренең берсе булып тора, бүгенге көндә Россия һәм чит ил инвесторларын җәлеп итү өчен бөтен кирәкле шартларга ия.

Икътисади сәясәт өлкәсендә җирле үзидарә органнарының төп бурычы булып икътисадны ныгыту һәм алга таба үстерү, предприятиеләрнең тотрыклы эшләве өчен уңай мохит булдыру, районда көн итүчеләрнең тормыш дәрәҗәсен яхшырту тора.

Балык Бистәсе муниципаль районы икътисади-географик яктан отышлы урынны били:

- Чулман елгасы ярында урнашкан, Балык Бистәсе район үзәгендә утыру тирәнлеге 9 метрга кадәр булган зур йөк судноларын кабул итәргә сәләтле причал бар;

- “Казан” халыкара аэропортына якын булу (80 км);

- район территориясеннән федераль әһәмияттәге М 7 Казан-Яр Чаллы һәм Казан-Оренбург трассалары уза.

Балык Бистәсе муниципаль районы 1927 елда төзелгән, Татарстан Республикасының үзәк өлешендә Чулман елгасының уңъяк ярында урнашкан. Район көнбатыштан Лаеш, төньяк-көнбатыштан Питрәч һәм Теләче районнары белән чиктәш, төньяктан - Саба, көнчыгыштан - Мамадыш районнары белән.

Район территориясендә Чулман (Кама) елгасы, Чулманга коючы Бәтке, Әшнәк, Суша һәм Шумбут инешләре ага.

Район территориясе 2041,4 кв. км, шул исәптән урман фонды җирләре 537,01 кв. км, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең мәйданы 1189,1 кв. км тәшкил итә.

Район территориясендә 1 шәһәр һәм 26 авыл җирлеге урнашкан. Районда барысы 77 торак пункт.

**Таблица №1. ББМР ның авыл җирлекләре**

| № | Җирлекнең исеме (атамасы) | Административ үзәге | Торак пунктлар саны | Халык саны (кеше), 2019 елның 1 гыйнварына |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Балык Бистәсе шәһәр җирлеге | Балык Бистәсе штп. | 1 | 7670 |
| 2 | Анатыш авыл җирлеге | Анатыш авылы | 2 | 681 |
| 3 | Балыклы Чүкәй авыл җирлеге | Балыклы Чүкәй авылы | 3 | 671 |
| 4 | Биектау авыл җирлеге | Биектау авылы | 5 | 1136 |
| 5 | Олы Елга авыл җирлеге | Олы Елга авылы | 4 | 1028 |
| 6 | Бәтке авыл җирлеге | Бәтке авылы | 4 | 397 |
| 7 | Олы Кульга авыл җирлеге | Олы Кульга авылы | 4 | 490 |

| № | Җирлекнең исеме (атамасы) | Административ үзәге | Торак пунктлар саны | Халык саны (кеше), 2019 елның 1 гыйнварына |
|---|---|---|---|---|
| 8 | Зур Мәшләк авыл җирлеге | Зур Мәшләк авылы | 3 | 645 |
| 9 | Олы Әшнәк авыл җирлеге | Олы Әшнәк авылы | 2 | 465 |
| 10 | Олы Солтан авыл җирлеге | Олы Солтан авылы | 3 | 271 |
| 11 | Казак Чаллысы авыл җирлеге | Казак Чаллысы авылы | 6 | 499 |
| 12 | Корноухово авыл җирлеге | Корноухово авылы | 4 | 566 |
| 13 | Күгәрчен авыл җирлеге | Күгәрчен авылы | 2 | 1013 |
| 14 | Күки авыл җирлеге | Күки авылы | 1 | 504 |
| 15 | Котлы Бөкәш авыл җирлеге | Котлы Бөкәш авылы | 4 | 1955 |
| 16 | Масловка авыл җирлеге | Масловка авылы | 1 | 625 |
| 17 | Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге | Югары Тегермәнлек авылы | 2 | 1040 |
| 18 | Яңа Арыш авыл җирлеге | Яңа Арыш авылы | 1 | 693 |
| 19 | Полянка авыл җирлеге | Полянка авылы | 1 | 796 |
| 20 | Рус Әшнәге авыл җирлеге | Рус Әшнәге авылы | 1 | 385 |
| 21 | Троицкий Урай авыл җирлеге | Троицкий Урай авылы | 2 | 522 |
| 22 | Уракчы авыл җирлеге | Уракчы авылы | 4 | 491 |
| 23 | Шумково авыл җирлеге | Шумково авылы | 4 | 433 |
| 24 | Шомарбаш авыл җирлеге | Шомарбаш авылы | 4 | 457 |
| 25 | Шумбут авыл җирлеге | Шумбут авылы | 4 | 511 |
| 26 | Югары Ырга авыл җирлеге | Югары Ырга авылы | 2 | 307 |
| 27 | Балтач авыл җирлеге | Балтач авылы | 2 | 801 |

2019 ел башына район халкының гомуми саны 25052 кешене тәшкил итте, шуның 53% ы – хезмәткә яраклы яшьтә, 32% ы хезмәткә яраклы яшьтән узган һәм 15% ы - балалар. Милли составы: 79% - татарлар, 20% - руслар һәм 1% - башка милләт вәкилләре.

**Таблица № 2. ББМР халкы саны динамикасы**

| Халык саны (кеше), ел башына | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| *2006* | *2007* | *2008* | *2009* | *2010* | *2011* | *2012* |
| 28400 | 28400 | 28300 | 28120 | 28100 | 27964 | 27315 |
| *2013* | *2014* | *2015* | *2016* | *2017* | *2018* | *2019* |
| 26910 | 26560 | 26233 | 26096 | 25774 | 25440 | 25052 |

### 3.2.ББМР ның төп социаль-икътисади күрсәткечләре

Район икътисады авыл хуҗалыгы, төзелеш тармагы, сәнәгать, күпләп һәм ваклап сату предприятиеләре һәм оешмалары тарафыннан тәкъдим ителгән. 2018 елда икътисади эшчәнлекнең барлык төрләре буенча тулай территориаль продукт (ТТП) 14%ка арткан һәм 6,9 млрд. сум тәшкил иткән (җан башына исәплләгәндә - 273,8 мең сум).

Районда агросәнәгать комплексы системасы үсеш алган. Тулай территориаль продуктның 39,4%ы агросәнәгать комплексында җитештерелә. 2018 елда авыл хуҗалыгының тулай продукциясе күләме 12%ка кимеде һәм 2 117 млн. сум тәшкил итте.

Үсемлекчелек өлкәсендә соңгы елларда югары табышлы культуралар (кукуруз, көнбагыш һәм рапс) үстерүгә өстенлек бирелә. Уңыш: кукуруз - 42,3 ц/га, көнбагыш - 19,2 ц/га, рапс - 11,8 ц/га.

Район республикада хуҗалык итүнең кече формаларын үстерү буенча алдынгы позицияләрне били. Район территориясендә 46 гаилә фермасы эшли. Тагын 5е – төзелеш стадиясендә.

Терлекчелек өлкәсендә сөт җитештерү югары үсеш алган. Мисалга, районда гамәлдә булган 46 гаилә фермасының 22се сөт юнәлешендә эшли. Көн саен район 43 тонна сөт сава, 2017 ел белән чагыштырганда бу 1 тоннага күбрәк яисә 102% ны тәшкил итә.

Мөгезле эре терлекләр (МЭТ) саны 13 077 баш тәшкил итә, шул исәптән 4 223 баш сыер.

Авыл хуҗалыгы үсешенә “Кулон-Агро” ҖЧҖ, “Агрокам” ҖЧҖ, “ВЗП Балык Бистәсе” ААҖ, “Солтан” агрофирмасы ҖЧҖ, “Логос” ҖЧҖ кебек предприятиеләр зур өлеш кертәләр.

**Таблица № 3. 2014-2018 еллар чорында ББМР ның социаль - икътисади үсеше күрсәткечләренең үзгәрү динамикасын бәяләү**

| Күрсәткеч исеме (атамасы) | ЧОРЛАР | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел |
| Даими халык саны (ел башына), кеше | 26 233 | 26 096 | 25 774 | 25 440 | 25 052 |
| узган елга карата – % | 99,0 | 99,5 | 98,8 | 98,7 | 98,5 |
| Тулай территориаль продукт-барлыгы, млн. сум | 4 158,8 | 4 746,1 | 5 329,2 | 6 043,8 | 6 858,0 |
| узган елга карата – % | 128,2 | 114,0 | 112,3 | 113,4 | 114,0 |
| Эре һәм урта предприятиеләр буенча өстәмә кыйммәт күләме барлыгы, мең сум (факттагы бәяләрдә) | 574 012 | 593 826 | 632 628 | 746 018 | 961 313 |
| узган елга карата – % | 95,9 | 103,5 | 106,5 | 117,9 | 128,9 |
| Үзләре җитештергән төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм хезмәтләр күләме, млн. сум | 165,9 | 343,7 | 991,2 | 1 304,1 | 1 215,5 |
| узган елга карата – % | 97 | 207,2 | 288,4 | 131,6 | 93,2 |
| Сәнәгать җитештерүе индексы, % | 121,7 | 142,0 | 107,6 | 140,0 | 151,9 |
| Барлык категория хуҗалыкларда авыл хуҗалыгының тулай продукциясе,гамәлдәге бәяләрдә, млн. сум (авыл хуҗалыгы оешмаларында һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны да исәпкә алып) | 3093,2 | 4033,5 | 4139,5 | 4536,9 | 4691,9 |
| узган елга карата – % | 129 | 103 | 102,6 | 104,2 | 103,4 |
| Ашлык җитештерелде, мең т | 104,3 | 103,3 | 119,5 | 141,4 | 108,4 |
| Бөртеклеләр уңышы, ц/га | 24,3 | 23,1 | 28 | 32,7 | 23,6 |
| Сөт җитештерелде, тонналарда барлык төр хуҗалыкларда (а/х берләшмәләрендә, КФХ һәм ИП) | 13 851 | 14 359 | 15 123 | 16 675 | 16 915 |
| Мөгезле эре терлек (МЭТ) саны | 12 570 | 12 696 | 12 742 | 12 735 | 13 077 |
| Төп капиталга инвестицияләр күләме, млн. сум | | 1 139,4 | 1 674,8 | 1 299,5 | 1 176,6 |
| Төп капиталга инвестицияләр күләме (бюджет средстволарыннан тыш), млн. сум | 631,8 | 873,5 | 1 629,3 | 1 259,7 | 1 176,6 |

| Күрсәткеч исеме (атамасы) | ЧОРЛАР | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел |
| - инвестиция күләме (бюджетныкыннан башка) җан башына исәпләгәндә, мең сум | 23,6 | 33,3 | 63,22 | 49,52 | 46,97 |
| Торак йортларның гомуми мәйданын файдалануга тапшыру, кв.м. | 13 100 | 13 005 | 13 006 | 13 018 | 13 500 |
| узган елга карата – %, тиңдәшле чорга | 117,0 | 100,0 | 100,0 | 100,1 | 103,7 |
| Салым һәм салым булмаган керемнәр, мең сум | 168 960,3 | 175 079,5 | 198 236 | 212 999 | 237 367 |
| узган елга карата үсеш темпы, % | 122 | 104 | 113,2 | 107,4 | 111,4 |
| шул исәптән җан башына исәпләгәндә, сум | 6 440 | 6 709 | 7 691 | 8 372 | 9 474 |
| Ваклап сату товар әйләнеше күләме, млн. сум | 1 498,3 | 1 563,5 | 1 638,8 | 1 686,5 | 1 882,6 |
| узган елга карата – %, тиңдәшле чорга | 107,5 | 104 | 104,8 | 102,9 | 111,6 |
| Җан башына исәпләгәндә ваклап сату әйләнеше, мең сум | 57,12 | 59,91 | 63,58 | 66,29 | 75,15 |
| Халыкка түләүле хезмәт күрсәтүне тормышка ашыру күләме – барлыгы, млн. сум | 298,2 | 205 | 207,4 | 227,1 | 241,6 |
| Җан башына халыкка түләүле хезмәт күрсәтүне тормышка ашыру күләме, мең сум | 11,37 | 7,86 | 8,05 | 8,93 | 9,64 |
| Хезмәткә түләү фонды, млн. сум | 912,9 | 949,4 | 996,9 | 1 089,1 | 1 231,9 |
| узган елга карата – % | 104,2 | 104 | 105,0 | 109,3 | 113,1 |
| Эшләүчеләрнең исемлек буенча уртача саны | 4265 | 4200 | 4192,4 | 4 314 | 4 411 |
| узган елга карата – % | 93,9 | 98,5 | 99,8 | 102,9 | 102,2 |
| Уртача айлык хезмәт хакы, сум | 17 838,6 | 18 837,7 | 19 818,5 | 21 037 | 23 117 |
| узган елга карата үсеш темпы, % | 111 | 107 | 106,1 | 113,8 | 109,9 |
| Чор азагына теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе, % | 0,93 | 0,87 | 0,75 | 0,55 | 0,39 |

2018 елда үзләре җитештергән төяп җибәрелгән товарлар, чиста икътисади эшчәнлек төрләре буенча үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр күләме 1 215,5 млн. сум тәшкил итте. Сәнәгать җитештерүе индексы 151,9 % булды.

Районның алдынгы сәнәгать предприятиеләре булып “АПК Русский Мрамор»” ЯАҖ, “Балык Бистәсе ХПП” ҖЧҖ, “Кызыл Йолдыз урманы” ДБУ тора.

Төп капиталга инвестицияләр күләме 2018 ел нәтиҗәләре буенча 1 176,6 млн. сум тәшкил итте.

ББМРда "Клариус" ҖЧҖ (кларий җәене үрчетү заводы төзелеше), "КАЗ" Балык Бистәсе агрофирмасы" ҖЧҖ (авыл хуҗалыгы кошлары үрчетү), "Kisher" ҖЧҖ (кондитер әйберләре җитештерү проекты), "Эдем" ҖЧҖ ("Кама" юл буе кафесы), Володин Николай Вячеславович КФХ (карлыган үстерү) кебек инвесторлар җәлеп ителде.

Ваклап сатыла торган товар әйләнешенең үсеш темпы 111,6% тәшкил итте (күләм – 1 882,6 млн.сум), халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтүне тормышка ашыру – 106,4% (241,6 млн. сум).

Эшсезлек дәрәҗәсенең кимүе теркәлгән.

2018 ел нәтиҗәләре буенча районда уртача хезмәт хакы 23 117 сум тәшкил иткән.

Ел саен район халкы тарафыннан шәхси торак йортлар төзегәндә 300 млн. сумга якын инвестицияләр кертелә. 2018 елда 13,5 мең кв. метр торак төзелгән һәм файдалануга тапшырылган, бу-125 индивидуаль торак йорт. Халыкның торак белән тәэмин ителеше бер кешегә 30,8 кв.метрны тәшкил итә. Актив төзелеш Балык Бистәсенең "Төньяк" бистәсендә алып барыла, 185 торак йорт төзелде, электр, су белән тәэмин итү хәл ителде.

2018 елда консолидацияләнгән (бергә тупланган) бюджетның керемнәре 237,4 млн. сум тәшкил итә, 2017 ел дәрәҗәсенә карата 111,5%.

Социаль өлкәгә чыгымнарга килгәндә, аларның күләме республика дәрәҗәсендә билгеләнгән нормативлар нигезендә формалаштырыла. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: хуҗалык итүче субъектлар эшчәнлегеннән җирле бюджетка керемнәр арту, шулай ук бюджет оешмаларында бюджет акчаларын экономияләүдән киләсе бюджет елында җирле бюджетның гомуми күләмен арттырмый, чөнки законнар нигезендә бу очракта бюджет трансфертлары күләме азрак була (үзгәрмәгән чыгым вәкаләтләре булганда).

Үсеш бюджеты бик аз, бу күләмнәр хисабына инвестиция эре проектларын тормышка ашыру мөмкин түгел. Шуңа бәйле рәвештә, һичшиксез, бюджеттан тыш

инвестицияләрне җәлеп итү, шулай ук ББМР ның республика һәм федераль проектларда катнашуын киңәйтү аеруча зур игътибар таләп итә.

Шулай итеп, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне тиешле дәрәҗәдә хәл итү өчен, шулай ук үсеш бюджетын формалаштыру өчен ББМР ның иң җитди проблемаларыннан берсе булып бюджет кытлыгы һәм өстәмә салым һәм салым булмаган керемнәр булмау тора. Бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру өчен бюджет дисциплинасын яхшыртырга кирәк. Шулай ук финанслау лимитлары белән тәэмин ителмәгән вакыты чыккан кредиторлык бурычы, чыгымнар барлыкка килүне гамәлдән чыгарырга.

Финанс дисциплинасын яхшырту максатларында муниципаль унитар предприятиеләр эшчәнлегенә финанс контролен көчәйтергә һәм камилләштерергә кирәк.

ББМР территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы кайбер предприятиеләр башка муниципаль берәмлекләрдә теркәлгән, ә бу ББМР бюджетыннан төшеп калучы салым керемнәре өлеше турында сөйли.

## 4. ББМР ның көндәшлек өстенлекләре

### 4.1. Транспорт-логистика инфраструктурасы

Балык Бистәсе муниципаль районы Татарстан Республикасының үзәк өлешендә Чулман елгасының уң ярында урнашкан. Район Лаеш, Питрәч, Теләче, Саба һәм Мамадыш районнары белән чиктәш. Район үзәге Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы Татарстан Республикасы башкаласыннан 90 км, Яр Чаллы шәһәреннән 180 км, “Казан” халыкара аэропортыннан 80 км ераклыкта урнашкан.

Балык Бистәсе штп. да утыру тирәнлеге 9 метрга кадәр булган зур йөк судноларын кабул итәргә сәләтле причал бар, уртача бер сезонда 350 мең тоннага кадәр йөк уза. Пассажирларны утырту-төшерү өчен причаллы төзекләндерелгән яр буе да бар.

Район территориясе буенча федераль әһәмияттәге М-7 “Волга” - Мәскәү - Түбән Новгород - Казан - Уфа һәм Р-239 “Казан - Оренбург - Акбулак - Казахстан Республикасы белән чик” трассалары уза.

### 4.2. Файдалы казылмаларның булуы

Районда каты файдалы казылмалар базасы бар, алар известьле мелиорантлар һәм вак таш әзерләү өчен яраклы. Әлеге карьер эшләү нәтиҗәсендә кырларга ел саен 21 000 тонна известьташ кертелә, ел саен авыл җирлекләрендә авыл эчендәге юлларның 10 км ына вак таш түшәлә. Карьерның җитештерү ресурсы 2027 елга кадәр исәпләнгән. Әлеге карьерда ел саен 7000 тоннага хәтле вак таш чыгарыла.

### 4.3. Энергетика

Район территориясендә Татарстан Республикасының биш муниципаль районыннан (Саба, Теләче, Мамадыш, Питрәч һәм Балык Бистәсе) кулланучыларны электр белән тәэмин итәргә сәләтле Котлы Бөкәш подстанциясе урнашкан һәм ул республиканың ике энергорайонын - Түбән Каманы, Казанны бәйли. Моннан тыш ул Идел буе һәм Урал энергосистемалары арасында мөһим бәйләүче звено булып тора. “Котлы Бөкәш” 220 кВ ПС нә өр-яңа энергонәтиҗәле һәм экологик җиһазлар кулланып үткәрелгән реконструкция нәтиҗәсендә кулланучыларны электр белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы арта, куллануга чыгымнар кими. Объектның куәте 146,8 МВА тәшкил итә. Әлеге объектның энергетика ресурслары безнең районга капитал салырга теләк белдерүче инвесторларның яңа җитештерү куәтләрен электр энергиясе белән тәэмин итә ала.

**5. Балык Бистәсе муниципаль районын үстерүнең төп юнәлешләре. Проблемалар һәм аларны хәл итү юллары**

Балык Бистәсе муниципаль районының 2021 елга кадәр үсешенең стратегик максаты: "ТТП ны 34% ка арттыру белән район икътисадын үстерү нигезендә Балык Бистәсе муниципаль районы халкының тормыш сыйфатын күтәрү".

Бу максатка ирешүнең уңышлылыгын тәэмин итү өчен хәрәкәт өч юнәлештә алып барылырга тиеш:

икътисадны үстерү,

социаль өлкәне үстерү,

территория үсеше.

ББМР Стратегия 2030 да каралган икътисади зоналаштыру нигезендә Чулман алды икътисади зонасына керә.

Стратегия 2030 кысаларында Казан агломерациясенә керә торган Чулман алды икътисади зонасының стратегик үсешенең өстенлекле юнәлеше – шәһәр һәм авыл җирлекләрен үстерү территорияләрен интеграцияләү.

ББМР Стратегиясен эшләүгә хәтле муниципаль районнар җитәкчеләре һәм белгечләре, авыл җирлекләре башлыклары һәм Чулман алды икътисади зонасына керүче бизнес җәмәгатьчелеге вәкилләре катнашында стратегик сессия уздыру эше барды.

Стратегик сессиядә муниципаль районның социаль-икътисади үсешен тоткарлый торган проблемалар, шулай ук үсешнең төп юнәлешләре буенча хәл итү юллары билгеләнде.

Кайбер проблемаларны хәл итү ББМР дәрәҗәсендә аларны бетерү буенча идарә итү һәм хуҗалык карарларын кабул итү яссылыгында гына түгел, ә республика һәм Россия Федерациясе дәрәҗәсендә мондый карарлар кабул итү системасында да ята.

**5.1. Икътисадны үстерү**

**Максат**: ТТПны арттыру һәм районның инвестицион җәлеп итүчәнлеген күтәрү, яңа эш урыннары булдыру һәм халыкның мәшгульлек проблемаларын хәл итү.

**Бурычлар:**

-агросәнәгать комплексын үстерү;

- сәнәгатьне үстерү;

- туризмны үстерү.

**Сәнәгать мәйданчыкларын үстерү һәм резидентлар җәлеп итү.**

Муниципаль район территориясенә инвесторлар җәлеп итү буенча актив эш алып барыла.

Инвестиция проектлары арасында түбәндәге проектларны аерып күрсәтергә мөмкин:

- “Kisher” ҖЧҖ – Зур Машляк авылында элеккеге административ бина һәм ашханә базасында кондитер эшләнмәләре җитештерү. Белдерелгән инвестицияләр күләме 100 млн. сум тәшкил итә. 30 эш урыны булдыру планлаштырыла.

- “Балык Бистәсе ХПП” ҖЧҖ икмәк кабул итү пунктын модернизацияләүгә кереште. Өстәмә 40 эш урыны булдырылды. Предприятие территориясендә “Прикамье” сәнәгать мәйданчыгы төзелде. “Рав-Агро” ҖЧҖ һәм “РС-Агро” ҖЧҖ резидентлары белән хезмәттәшлек итү нияте хакында килешүләр төзелде.

- Элеккеге кирпеч заводы территориясендә сәнәгать мәйданчыгы төзелешенә керештеләр. Бүгенге көндә “Клариус” ҖЧҖенең беренче резиденты кларий җәене үрчетү заводы төзелешенә тотынды. Игълан ителгән инвестицияләр күләме 15 млн. сум.

-“Эдем” ҖЧҖ. Казан-Оренбург трассасында Саескан тавы авылында юл буендагы заманча "Кама" кафесын кулланылышка тапшырдылар. Кертелгән инвестицияләр күләме 40 млн. сум тәшкил итте, 26 эш урыны булдырылды.

Агросәнәгать комплексында түбәндәге инвестиция проектлары гамәлгә ашырыла:

-“Кулон Агро” ҖЧҖ нең 500 башка исәпләнгән сөтчелек комплексының 3 нче этабы төзелеше.

- 1000 баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән симертү мәйданчыгы төзелеше.

- “КАЗ”Балык Бистәсе агрофирмасы” ҖЧҖ. Бүгенге көндә фермадагы терлекләрнең баш саны 1 000 нән артык. Төзелешнең беренче этабына игълан ителгән инвестицияләр суммасы 6,0 млн. сум тәшкил итә. 3 эш урыны булдырылды, тагын 5 эш урыны булдыру күздә тотыла.

- “Фуд Альянс” ҖЧҖ - 100 гектар җирдә җир җиләге, пекин кәбестәсе, томатлар үстерү буенча теплица комплексы төзелеше. 2018 елда 15 эш урыны булдырылган. Проектка 17 млн. сум капитал салынган, киләчәктә 40 эш урынына кадәр җиткерү ниятләнә. Әзер продукцияне саклау өчен яшелчәсаклагыч төзү планлаштырыла.

- якорьлы резиденты булган “Татарстан гектары” инвестиция проекты – “Фуд Альянс” ҖЧҖ. Проектның максаты – 200 гектар җирдә җир җиләге, карлыган, кура җиләге үстерү буенча кооператив төзү. Проект шулай ук җитештерелгән продукцияне эшкәртүне дә үз эченә ала.

Заманча крестьян-фермер хуҗалыклары төзелә. Мәсәлән, Анатыш авыл җирлеге территориясендә Володин Вячеслав Николаевич КФХ 24 гектар мәйданда карлыган үстерү белән шөгыльләнә. 2018 елда 300 кг уңыш алынган. Проектның беренче этабына игълан ителгән инвестицияләр суммасы 10 млн. сум тәшкил итте. 3 эш урыны булдырылды, 6 эш урыны булдыру планлаштырыла.

Борисов Тимур Валерьевич КФХ Африка җәене үстерү белән шөгыльләнә. 2018 елда 1500 кг балык сатылган. Балык эшкәртү җиһазлары сатып алынган. Балык үрчетү – маймыч үстерү алып барыла.

Сәлахов Рамил Камил улының крестьян-фермер хуҗалыгы Олы Солтан авыл җирлеге территориясендә алма һәм җир җиләге үстерә. 1,5 тонна күләмендә беренче уңыш җыеп алынган. Бакча кишәрлегенең мәйданын 30 га җиткерергә уйлыйлар.

### 5.2. Агросәнәгать комплексын үстерү

Балык Бистәсе муниципаль районының агросәнәгать комплексы үсешенең нәтиҗәлелеге күп яктан район халкының тормыш дәрәҗәсен билгели. Район

икътисадында авыл хуҗалыгы юнәлешендәге предприятиеләрнең тоткан урыны югары булуы моны аеруча әһәмиятле итә.

2018 елда авыл хуҗалыгы продукциясенең тулай күләме 2 миллиард 117 миллион сум тәшкил итте, бу узган елга караганда 12% ка кимрәк. Авыл хуҗалыгы продукциясен сату күләме 37% ка арткан һәм 1 миллиард 730 миллион сум тәшкил иткән. Продукция сатудан кергән табыш 1 гектар сөрүлеккә 20,5 мең сум тәшкил иткән.

ТР АПКсы табышы күләмендә тоткан урынының уңай динамикасы күзәтелә. Әгәр 2017 елда ул 1,25% булса, 2018 елда 1,61%. 2019 елга фараз – аны республика күләмендә 1,7 %ка җиткерү.

Бөртекле культуралар 46 мең гектар мәйданда игелде. 108,4 мең тонна ашлык җыелган. Бөртеклеләрнең уртача уңышы гектардан 23,6 центнер тәшкил итә.

Узган ел белән чагыштырганда 103% тупас һәм сусыл азык әзерләнгән, бу бер баш шартлы терлеккә 32,6 центнер азык бирәмлеге дигән сүз.

Үсемлекчелек буенча 2018 ел рейтингы йомгаклары буенча район 26 урынны били.

Соңгы елларда үсемлекчелек тармагында үзгәрешләр булды, бөртеклеләрне игү технологиясе сыйфат ягыннан яңа дәрәҗәгә күтәрелде, бөртекле культураларның яңа төрләре һәм сортлары барлыкка килде.

2018 елда бөртеккә игелгән кукурузның уңдырышы – 42,3 ц/га. Барлыгы 1240 гектардан 5,2 мең тонна бөртек җыелган. Иң югары күрсәткечләргә "Балык Бистәсе азык-төлек корпорациясе" ҖЧҖ ирешә – уңыш гектардан 200 га мәйданда 48 ц/га.

Район буенча көнбагыш игү мәйданы - 3355 га, уңдырыш - 19,2 ц/га. Аеруча уңышлы нәтиҗәне "Логос" ҖЧҖ күрсәтте: 1455 га мәйданда 29,0 ц/га уңыш алуга ирештеләр, тулай җыем эшкәртелгәннән соң 4219 тонна булды.

Соңгы елларда рапс уңышы күтәрелде. 2018 елда ул тулай җыем 5314 тонна булганда 11,8 ц/га тәшкил итте.

Киләчәктә югары нәтиҗәле культуралар мәйданнары акрынлап киңәячәк.

Район авыл хуҗалыгының иң мөһим тармакларының берсе - терлекчелек.

2018 елда мөгезле эре терлекләрнең баш саны 13 077 (2017 елга карата 103%) булды, шул исәптән 4 223 сыер, шуларның 3 127 се – сөтчелек сыерлары.

16 915 тонна сөт җитештерелгән, ягъни 2017 елга карата 102 %, алдагы елга карата ит 100 % - 3125 тонна. Бер сыердан уртача савым 5409 кг тәшкил итте, ул 10%ка күтәрелде.

Сөт җитештерүне үстерүдә 2018 елда "Кулон Агро" ҖЧҖенең өстәмә 500 баш сыерга исәпләнгән сөт комплексының икенче чиратын файдалануга тапшыру зур роль уйнады, бу хуҗалыкта көн саен 10 тоннага якын сөт савалар. Киләчәктә 2020 елда "Кулон Агро" ҖЧҖендә тагын 500 башка исәпләнгән терлекчелек комплексының өченче чиратын төзи башлау планлаштырыла.

Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүгә районның шәхси ярдәмче хуҗалыклары зур өлеш кертә, аларда бүген 7249 баш мөгезле эре терлек бар, шул исәптән 2661 сыер, тагын 5208 сарык һәм кәҗә, 36 меңнән артык кош-корт. Гомуми баш санының артуы 103% тәшкил итте. МЭТ саны шул ук дәрәҗәдә сакланган. Хисап чорында алар 8362 тонна сөт һәм тере авырлыкта 923 тонна ит җитештергән һәм саткан.

Районда фермерлык хәрәкәте яңа сыйфатларга ия була бара, күп хуҗалыклар гаилә терлекчелек фермалары булдырды.

2018 ел йомгаклары буенча гаилә фермалары саны 46 булды, алар арасында 22 се – сөтчелек юнәлешендә, 12 се - мөгезле эре терлек симертү буенча, 4 се - атлар үрчетү буенча, 2 се - кошчылык фермасы, 2 се - сарыкчылык фермасы, 2 се - бөртекле культуралар җитештерү буенча һәм 2 се - җиләк культуралары үстерү буенча. Тагын 5 есе төзелеш стадиясендә.

Казак Чаллысы авылында "Агрокам" ҖЧҖ енең дуңгызчылык комплексы ныклы үсеш ала, анда дуңгызлар саны 7245 башка җиткән, бу 2017 ел дәрәҗәсеннән 873 башка күбрәк. 2018 елда 1139 тонна дуңгыз ите җитештерелде. Актив биоөстәмәле

азык куллану нәтиҗәсендә дуңгызларның тәүлеклек уртача артымы 750-800 граммга җитә.

Гаилә фермаларының актив үсеше һәм җәлеп итүчәнлеге күп яктан дәүләт ярдәменә бәйле. Гаилә фермаларын үстерүгә 65 миллион сумнан артык күләмдә 11 грант алынган. 2018 елда авыл хуҗалыгы предприятиеләре тарафыннан барлыгы 262,9 миллион сумлык төрле субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме алынды, шул исәптән шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сөт җитештерүгә ярдәм итү өчен 8,2 миллион сум.

Авыл хуҗалыгы җитештерүендә белгечләр белән тәэмин ителеш 93% тәшкил итә. Югары уку йортларында аграр һәм ветеринария юнәлешендә 68 студент белем ала, әмма яшь белгечләрне авылга кайтару бик түбән дәрәҗәдә кала бирә.

Авыл хуҗалыгы өлкәсендә Стратегиянең бурычлары:

- 2021 елда авыл хуҗалыгы продукциясен сатудан акчалата керемне 2 млрд. сумга җиткерү, шул рәвешле бу 2015 елның база күрсәткеченнән 81 процентка артып китүне күрсәтә. 2030 елга акчалата керем 2,5 млрд. сумга кадәр җиткереләчәк, ягъни база күрсәткече 127 процентка артачак.

- районның авыл хуҗалыгы җитештерүендә уртача айлык хезмәт хакы дәрәҗәсен 2021 елга 20 мең сумга кадәр һәм 2030 елга 30 мең сумга җиткерү.

- 2030 елга ашлык җитештерүне 130 мең тоннага кадәр, бу 2015 елга караганда 26 процентка күбрәк булачак.

- ит җитештерүне 2021 елга 2580 тоннага кадәр, бу 2015 ел дәрәҗәсенә карата 110 процент булачак, ә 2030 елга бу күрсәткеч 2800 тоннага кадәр артачак, ә ул 2015 ел дәрәҗәсенә карата 119 процентны тәшкил итәчәк.

- сөт җитештерү күләмен 2021 елга 18000 тоннага җиткерергә, бу 2015 ел дәрәҗәсеннән 26 процентка күбрәк, 2030 елга - 20000 тонна, бу 2015 ел дәрәҗәсеннән 40 процентка күбрәк.

- 2021 елга мөгезле эре терлек санын 13300 башка җиткерергә, бу 2015 елга карата 105 процент, ә 2030 елга 15000 башка кадәр җиткерергә, бу 2015 елга карата 118 процент тәшкил итәчәк (2015 елда МЭТ саны 12681 баш иде).

- дуңгызлар санын 2021 елга 12000 башка (2015 елга карата 157 процент), ә 2030 елга - 14000 башка җиткерү.

- авыл хуҗалыгы культураларының уңдырышын 28 ц/га га кадәр (2015 елга карата - 117 процент), ә 2030 елга - 35 ц/га (2015 елга карата 152 процент) җиткерү.

**Агросәнәгать комплексы өлкәсендәге проблемалар:**

Авыл хуҗалыгы техникасының, җиһазларының югары дәрәҗәдә тузганлыгы;

Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре товарларына сатып алу бәяләренең түбән булуы;

Продукциянең үзкыйммәтенең югарылыгы;

Югары квалификацияле эшче кадрлар кытлыгы;

Агросәнәгать комплексында заманча технологияләрне куллануның җитәрлек дәрәҗәдә булмавы.

**Хәл итү юллары:**

Югары маржиналь культуралар мәйданнарын 2021 елга 14500 гектарга җиткерергә;

селекция-нәсел эшен сыйфат ягыннан яңа дәрәҗәгә күтәрергә;

КФХда һәм ШЯХларда җирләрдән файдалануның нәтиҗәлелеген арттырырга;

Хуҗалык җитәкчеләренең, белгечләренең һәм башка хезмәткәрләренең квалификациясен даими күтәрү;

Авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре арасында кооператив хәрәкәтен үстерү;

Югары уңдырышлы бөртекле культураларны игүне гамәлгә кертү (көзге арыш, бодай, кукуруз);

Югары җитештерүчән авыл хуҗалыгы машиналары сатып алу юлы белән авыл хуҗалыгы техникасы паркын яңартуның интенсивлыгын күтәрергә;

Качкалак авылында "Прикамье" агросәнәгать паркын - Гобәйдуллин К.Г. КФХын төзү (килешенү буенча);

“Кулон Агро” ҖЧҖенең 500 башка исәпләнгән өченче сөт комплексын төзү (килешенү буенча);

“ВЗП Балык Бистәсе” ААҖнең 200 башка исәпләнгән сыер абзарын реконструкцияләү (килешенү буенча);

Караганов М.В. КФХында 100 башка исәпләнгән сыер абзары төзү (килешенү буенча);

К.Г. Гобәйдуллин КФХында 100 баш сыерга исәпләнгән сыер абзары төзү (килешенү буенча);

Назимов Р.К. КФХында 100 башка исәпләнгән сыер абзары төзү (килешенү буенча);

Квалификацияле эшче көчләрне, шул исәптән яңа югары җитештерүчән, компьютерлаштырылган техникада эшли белә торган, дөньякүләм дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы җитештерүенең яңа заманча технологияләрен үзләштерергә сәләтле яшь белгечләрне, механизаторларны әзерләү.

**Таблица № 4. Агросәнәгать комплексын үстерү өлкәсендәге чаралар**

| № | Чара | Үтәү сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Югары маржиналь культуралар чәчүлекләрен 2021 елга 14500 гектарга җиткерергә | 2020-2021 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча), инвесторлар (килешенү буенча) | 54 000,0 | Бюджеттан тыш |
| 2 | Селекция-нәсел эшен сыйфат ягыннан яңа дәрәҗәгә күтәрергә | 2020-2021 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча), авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре (килешенү буенча) | 25 000,0 | Бюджеттан тыш |
| 3 | КФХда һәм ШЯХларда җирләрдән файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрергә - барлык авыл хуҗалыгы җирләре эшкәртелергә тиеш | 2020-2021 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча) | - | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Хуҗалык җитәкчеләре, белгечләре һәм башка хезмәткәрләрнең квалификациясен даими күтәрү | 2020-2021 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча) | 200,0 | ТР бюджеты , җирле бюджет |
| 5 | Авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре арасында кооператив хәрәкәтен үстерү | 2020-2021 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе, авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре | 20 000,0 | РФ бюджеты , бюджеттан тыш |
| 6 | Югары уңышлы бөртекле культураларны (көзге арыш, бодай, кукуруз) гамәлгә кертү | 2020-2030 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча), авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре (килешенү буенча) | 12 000,0 | бюджеттан тыш |
| 7 | Югары җитештерүчән авыл хуҗалыгы машиналары сатып алу юлы белән авыл хуҗалыгы техникасы паркын яңарту интенсивлыгын арттыру | 2020-2021 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча), авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре (килешенү буенча) | 2020-2021 еллар – 720 000,0 | РФ бюджеты , ТР бюджеты, бюджеттан тыш |
| 8 | Качкалак авылында “Прикамье” агросәнәгать паркын (К.Г. Гобәйдуллин КФХ) төзү | 2020-2021 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча), инвестор (килешенү буенча) | 150 000,0 | бюджеттан тыш |
| 9 | “Кулон Агро” ҖЧҖ енең 500 баш сыерга исәпләнгән өченче сөт комплексын төзү | 2020-2021 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча), инвестор (килешенү буенча) | 2020 - 80 000,0<br>2021 - 54 000,0 | РФ бюджеты , бюджеттан тыш |
| 10 | “ВЗП Балык Бистәсе” ААҖендә 200 башка исәпләнгән сыер абзарын реконструкцияләү | 2020 ел | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча), инвестор (килешенү буенча) | 86 000,0 | бюджеттан тыш |
| 11 | 100 башка исәпләнгән сыер абзары төзү | 2019-2020 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча), Караганов М.В. КФХ (килешенү буенча) | 15 000,0 | ТР бюджеты , бюджеттан тыш |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 12 | 100 башка исәпләнгән сыер абзары төзү | 2019-2020 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча), Гобәйдуллин К.Г. КФХ (килешенү буенча) | 10 000,0 | РФ бюджеты , ТР бюджеты, бюджеттан тыш |
| 13 | 100 башка исәпләнгән сыер абзары төзү | 2019-2020 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча), Назимов Р.К. КФХ (килешенү буенча) | 10 000,0 | ТР бюджеты, бюджеттан тыш |
| 14 | Квалификацияле эшче көчләрне, шул исәптән яңа югары җитештерүчән, компьютерлаштырылган техникада эшли белә торган, дөньякүләм дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы җитештерүенең яңа заманча технологияләрен үзләштерергә сәләтле яшь белгечләрне, механизаторларны әзерләү | 2020-2030 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча), "Балык Бистәсе агротехник көллияте " УҺББ ДАМУ (килешенү буенча) | 3 000,0 | ТР бюджеты, җирле бюджет |

Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүгә шулай ук шәхси ярдәмче хуҗалыклар да зур өлеш кертә, аларда бүген 7249 баш мөгезле эре терлек бар, шул исәптән 2661 сыер. Узган ел МЭТ саны 55 башка кимегән.

2018 елда алар тарафыннан 8362 тонна сөт һәм тере авырлыкта 923 тонна ит җитештерелгән. Авыл халкы өчен шәхси ярдәмче хуҗалыклар крестьян гаиләсе бюджетында һәрвакыт зур роль уйнады. Базар мөнәсәбәтләренә күчү, авылда кече эшкуарлыкны үстерү белән шәхси ярдәмче хуҗалыкларның әһәмияте кимемәде. Җәмәгать җитештерүендә җитештерүнең кискен кимүе шартларында күп төбәкләрдә ШЯХ авыл халкының көн күрүенең төп чарасына әйләнде.

Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны саклап калу һәм аны авыл җирлегендә үстерү өчен түбәндәге берничә чараны гамәлгә ашырырга кирәк:

ШЯХларны мәгълүмати консультация белән тәэмин итү;

Шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ярдәм итү программаларында катнашуда булышлык күрсәтү;

Арендага алынган пай җирләре исәбенә азык белән вакытында тәэмин итү;

Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны азык белән тәэмин итүне оештыру;

ШЯХларда җитештерелгән артык продукцияне сату өчен ярминкәләр оештыру.

**Таблица № 5. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү өлкәсендә чаралар**

| № | Чара | Үтәү сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | ШЯХларны мәгълүмати консультация белән тәэмин итү | 2020-2030 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча),җирле үзидарә органнары | - | - |
| 2 | Шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ярдәм итү программаларында катнашуда булышлык күрсәтү | 2020-2030 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча), җирле үзидарә органнары | - | - |
| 3 | Арендага алынган пай җирләре исәбенә азык белән үзвакытында тәэмин итү | 2020-2030 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча), җирле үзидарә органнары, авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре (килешенү буенча) | - | - |
| 4 | Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны азык белән тәэмин итүне оештыру | 2020-2030 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча), җирле үзидарә органнары, авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре (килешенү буенча) | - | - |
| 5 | ШЯХларда җитештерелгән артык продукцияне сату өчен ярминкәләр оештыру. | 2020-2030 еллар | ББМР БК, АХ һәм АТ идарәсе (килешенү буенча), җирле үзидарә органнары | - | - |

### 5.3. Сәнәгатьне үстерү

2018 елда үзләре җитештергән төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр күләме 1 млрд. 21 млн. сум тәшкил итте. Сәнәгать җитештерүе индексы 2017 ел дәрәҗәсенә карата 151,9% булды (2017 елда – 108,5%). Районның ТТП да сәнәгать тармагы предприятиеләренең өлеше 7,6% тәшкил итә.

“АПК Русский Мрамор" ЯАҖ ит эшкәртү предприятиесе продукциянең гомуми күләменең 50% тан артыгын сата. Предприятиенең куәте-елына 13 840 тонна әзер продукция. Бу предприятиедә төяп җибәрелгән товарлар күләме 619 млн. сум тәшкил итте. 127 эш урыны булдырылган. Уртача хезмәт хакы 32 мең сумнан артык.

Сәнәгать предприятиеләре арасында шулай ук үрнәк булырлык:

“Балык Бистәсе ХПП” ҖЧҖ. 2018 ел йомгаклары буенча җитештерелгән продукция күләме 26 млн. сум тәшкил итә. 43 эш урыны гамәлдә. Предприятиедә уртача хезмәт хакы - 28,2 мең сум.

“Кызыл Йолдыз урман” ДБУ. Предприятие ел саен 30 мең куб метрдан артык кыйммәтле агач әзерли.

### 5.4. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү

Кече эшкуарлыкның үсешендә югары күрсәткечләренә ирешү районның икътисади алгарышында һәм социаль тотрыклылыгында мөһим фактор булып тора. Район икътисадының үсеше шактый дәрәҗәдә кече һәм урта эшкуарлыкның нәтиҗәлелеген арттыруга бәйле.

Кече һәм урта эшкуарлыкның район икътисадына керткән өлеше елдан-ел зурая бара. Тулай территориаль продуктта кече һәм урта эшкуарлык продукциясе өлеше 36,5% ны тәшкил итә.

Эшкуарлык төрләре структурасында иң зур өлешне сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәтләре (40%), авыл, урман хуҗалыгы, аучылык, балык тоту һәм

балык үрчетү (22%), транспорт һәм элемтә (18%), төзелеш (5%), эшкәртү производстволары (4%), башка эшчәнлек (11%) алып тора.

Район территориясендә 678 эшкуарлык субъекты үзләренең хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыра, шул исәптән 122 кече һәм микропредприятие, 1 урта һәм 555 индивидуаль эшкуар, аларда 1,6 меңнән артык граждан хезмәт куя.

Җитештерелә торган продукция, эшләр һәм хезмәтләр күләме арта, яңа технологияләр кертү хисабына аларның ассортименты һәм сыйфаты яхшыра. Бюджетның барлык дәрәҗәләренә салым керемнәре арта, эшкуарларның бизнесны цивилизацияле алып баруга омтылышы арта бара.

Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан 2018 елда 53,5 млн. сум күләмендә салым керде, 2017 ел белән чагыштырганда үсеш 48% тәшкил итте. 2018 елда район бюджетының кече һәм урта бизнес субъектларыннан керем өлеше 28% тәшкил итте.

2018 ел нәтиҗәләре буенча кече һәм урта предприятиеләрнең әйләнеше 2753 млн. сум тәшкил итә, бу алдагы елга караганда 10,5 процентка күбрәк.

Район буенча кече предприятиеләрдәге 1 хезмәткәрнең уртача хезмәт хакы 13 261 сум тәшкил иткән, бу узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 10,4% ка күбрәк.

Балык Бистәсе муниципаль районының инвестиция җәлеп итүчәнлеген арттыру максатларында "2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү" программасы кысаларында сәнәгать мәйданчыкларын урнаштыру өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата түбәндәге күләмнәрдә аренда түләвен түләү буенча ташлама билгеләнгән: 1 нче аренда елында - аренда шартнамәсендә билгеләнгән еллык аренда түләве күләменең 20% ы, 2 нче ел -40% ы, 3 нче ел - 60% ы, 4 нче елда - 80% ы, 5 нче елда – 100%.

**Бурычлар:**

1.Кече һәм урта бизнеска ярдәм итү өчен инфраструктура объектларын булдыру һәм үстерү;

2. Эш башлаучы эшкуарларга ярдәм;

3. Сәүдә һәм кулланучылар базарын үстерү;

4. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә норматив-хокукый җайга салуны камилләштерү;

5. Кадрлар потенциалын ныгыту, эшкуарның уңай образын булдыру

**Көтелә торган нәтиҗәләр:**

- районның тулай территориаль продуктында кече һәм урта эшкуарлык продукциясе өлешен 2021 елга 41,9% ка кадәр, 2030 елга 49,2% ка кадәр арттыру.

- гамәлдә булган кече һәм урта предприятиеләрне саклап калу һәм яңа предприятиеләр булдыру, бу эш урыннары санын арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

- кече һәм урта эшкуарлыкта эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәт хакы дәрәҗәсен минималь куллану бюджеты күләменнән ким булмаганча саклап калу.

**Сәнәгать һәм КУЭ өлкәсендәге проблемалар:**

Зур җитештерү куәтләренең булмавы.

Эшлеклелек активлыгының түбән булуы.

Җитештерелгән продукцияне эшкәртү булмау.

Хезмәт ресурсларының сыйфатының түбән дәрәҗәсе.

Үсеш алган инфраструктура булмау.

КУЭ субъектлары өчен кредит продуктларының югары процент ставкасы.

**Хәл итү юллары:**

Кондитер әйберләре җитештерү буенча “Kisher” ҖЧҖ проектын тормышка ашыру (килешенү буенча),

“Балык Бистәсе ХПП” ҖЧҖенең икмәк кабул итү пунктын модернизацияләү (килешенү буенча),

"Клариус" ҖЧҖнең кларий җәене үрчетү буенча завод төзелеше (килешенү буенча).

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать паркларын булдыру һәм үстерү.

Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең кече һәм урта бизнес субъектларын яклауның төрле программаларында катнашуына булышлык күрсәтү.

**Таблица № 6. Сәнәгать һәм КУЭ ны үстерү өлкәсендәге чаралар**

| № | Чара | Үтәү сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кондитер әйберләре җитештерү буенча “Kisher” ҖЧҖ проектын тормышка ашыру | 2020 ел | ББМР БК, инвестор (килешенү буенча) | 75 000 | Бюджеттан тыш |
| 2 | “Балык Бистәсе ХПП” ҖЧҖенең икмәк кабул итү пунктын модернизацияләү | 2020 ел | ББМР БК, инвестор (килешенү буенча) | 20 000 | Бюджеттан тыш |
| 3 | "Клариус" ҖЧҖнең кларий җәене үрчетү буенча завод төзелеше | 2020 ел | ББМР БК, инвестор (килешенү буенча) | 5 000 | Бюджеттан тыш |
| 4 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать паркларын булдыру һәм үстерү. | 2020-2030 еллар | ББМР БК, җирле үзидарә органнары | - | - |
| 5 | Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең кече һәм урта бизнес субъектларын яклауның төрле программаларында катнашуына булышлык күрсәтү | 2020-2030 еллар | ББМР БК, җирле үзидарә органнары | - | - |

**5.5. Туризмны үстерү**

Балык Бистәсе муниципаль районында туризм икътисади һәм социаль проблемаларны хәл итүдә мөһим роль уйный. Әлеге юнәлешне үстерү өстәмә эш урыннары булдыруга, икътисади яктан актив халыкның мәшгульлеген үстерүгә, туризм белән чиктәш тармакларда эшкуарлык активлыгын арттыруга (туристик компанияләр хезмәтләре, кунак урнаштыру чаралары, транспорт, элемтә, сәүдә, сувенир һәм башка продукция җитештерү, туклану, авыл хуҗалыгы, төзелеш), мәдәни мирас объектларын реставрацияләүгә һәм территорияләрне төзекләндерүгә инвестицияләр җәлеп итүгә булышлык итә.

Районның туристлар җәлеп итүчәнлеге ягыннан өстенлекләре: районның Чулман ялы буенда урнашуы, күп санлы күлләр һәм елгалар. Урындагы җирләр бәһасез тарихны саклый - бүгенге көнгә кадәр басуларны һәм Чулман үзәнен эшкәрткәндә табыла торган мамонтларның бәрмәтешләреннән башлап халкы Явыз Иванның басып алу сәясәтенә ахыргача каршы торырга тырышкан Чаллы шәһәрлеген тәмамлап.

Хәзерге вакытта балык тоту, аучылык, авыл, мәдәни-танып-белү һәм эко-туризм район өчен туризмның перспективалы төрләре булып тора.

Регион өчен балык туризмы – аерым тема. Җирле сулар балыкларга бай, Чулман ярларында да, күп санлы күлләрдә дә балык тотарга була, һәм моны ел әйләнәсе эшләү мөмкинлеге бар.

ББМР өчен абсолют яңа юнәлеш – Степановка авылында урнашкан "Кыргый ферма" фермер хуҗалыгы тарафыннан каралган эко-туризмны үстерү. 2014 елда “Кыргый ферма” эко-туристлык паркы” проектын тормышка ашыру башланды.

Бүгенге көндә парк территориясендә 100 баштан артык кыргый хайван (тимгелле боланнар һәм маралллар) асрала. Бу юнәлеш район өчен эко-туризмны һәм авыл туризмын үстерүгә мөмкинлек бирәчәк. Булдырылган эш урыннары саны – 7 берәмлек. 35 берәмлек эш урыны булдыру планлаштырыла.

**Районда туризмны үстерү проблемалары:**

- районның табигый-ресурс һәм тарихи-мәдәни потенциалын җитәрлек дәрәҗәдә позицияләү булмау;
- район бренды булмау;
- үсеш алган туристлык инфраструктурасы булмау.

**Хәл итү юллары:**

Балык Бистәсе муниципаль районының уңай туристик имиджын формалаштыру, көндәшлеккә сәләтле туристик продукт булдыру, перспективалы туристик базарларда алга этәрү;

туризм өлкәсендә реклама-мәгълүмат эшчәнлеге алып бару;

туристлык һәм тәэмин итүче инфраструктураны үстерү;

районда туризмның өстенлекле төрләрен үстерү. Мәсәлән, Степановка авылында “Сафари Парк”ны үстерү. Монда туристлар безнең полоса өчен сәер булган хайваннар – Алтайдан кайтарылган мараллар һәм тимгелле боланнарны күзәтә һәм карый ала. Туристлар өчен "Сафари Парк" буйлап сәяхәт оештырылачак, һәвәскәрләр өчен монда шулай ук аерым билгеләнгән территорияләрдә төрле юнәлешләрдә аучылык хуҗалыклары оештырылган;

туризм һәм рекреация өлкәсендә инвестицион активлыкны күтәрү өчен уңай шартлар тудыру;

Балык Бистәсе муниципаль районында туризмны үстерүнең муниципаль программасын эшләү. Муниципаль-хосусый партнерлыкның программа-максатчан методын һәм механизмнарын куллану ачыкланган проблемаларны хәл итүнең һәм туризмның ресурс потенциалын файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрүнең иң нәтиҗәле ысулы булып тора.

**Таблица № 7. Туризмны үстерү өлкәсендә чаралар**

| № | Чара | Үтәү срoклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | "Сафари Парк" кору | 2020-2021 еллар | ББМР БК, инвестор (килешенү буенча) | - | Бюджеттан тыш |
| 2 | Туризм өлкәсендә реклама-мәгълүмат эшчәнлеге (үткәрү) алып бару | 2020-2021 еллар | ББМР БК, җирле үзидарә органнары | - | - |
| 3 | Сувенирлар һәм магнитиклар рәвешендә район брендын булдыру | 2020-2021 еллар | ББМР БК | - | Бюджеттан тыш |
| 4 | Арендага кирәкле инвентарь, шулай ук техника (квадратцикллар, кар чаналары һ.б.) биреп килүчеләр өчен балык тоту оештыру | 2020-2030 еллар | ББМР БК | - | Бюджеттан тыш |
| 5 | Туризм һәм рекреация өлкәсендә инвестицион активлыкны күтәрү өчен уңай шартлар тудыру | 2020-2030 еллар | ББМР БК, җирле үзидарә органнары | - | Бюджеттан тыш |
| 6 | Туристлык һәм тәэмин итүче инфраструктураны үстерү | 2020-2030 еллар | ББМР БК, җирле үзидарә органнары | - | Бюджеттан тыш |

### 5.6. Кулланучылар базарын үстерү

2019 елның 1 гыйнварына Балык Бистәсе муниципаль районы буенча 229 предприятие сәүдә эшчәнлеге алып бара. 2018 елда 3 кибет ачылды. 2018 елда сәүдә предприятиеләренең товар әйләнеше 1737 млн. сум тәшкил иткән, узган ел белән чагыштырганда үсеш 103%, шуларның 1389,8 млн. сумы азык-төлек товарлары төркеменең товар әйләнеше, 347 млн. сумы азык-төлек булмаганнарныкы. Районның бер кешесенә 2018 елда 68,3 мең сумлык товар сатылган.

Муниципаль район территориясендә товарларның азык-төлек булмаган төркемен сату буенча 1 базар урнашкан. Базар сәүдәсенең товар әйләнеше 2018 елның 12 аенда 364,5 млн. сум тәшкил иткән, 2017 ел белән чагыштырганда 4%ка

кимегән. Базарның товар әйләнеше муниципаль районның товар әйләнешенең гомуми күләменең 21 % ын тәшкил итә.

Стационар сәүдә предприятиеләрендә эшләүчеләр саны 1007 кеше. 2018 елда уртача хезмәт хакы 11570 сум тәшкил итте, узган ел дәрәҗәсенә карата үсеш 111,6%.

Балык Бистәсе муниципаль районында, базарларны исәпкә алып, 13556,3 квадрат метр сәүдә мәйданнары исәпләнә. Мең кешегә сәүдә мәйданының 533 квадрат метры туры килә.

Районда 560 утырып туклану урыны булган 13 җәмәгать туклануы предприятиесе эшли. Җәмәгать туклануы предприятиеләренең товар әйләнеше 58,8 млн. сум тәшкил итте, 2017 ел дәрәҗәсенә карата 104% үсеш. Бер кешегә 2311,3 сумлык җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгән. Җәмәгать туклануы предприятиеләрендә эшләүчеләр саны 52 кеше. 2018 елда уртача хезмәт хакы 11215 сум тәшкил итте, 2017 ел дәрәҗәсенә карата үсеш 111,2%.

Районда халыкка көнкүреш хезмәтләре күрсәтү буенча 29 предприятие эшли. 2018 елда әйләнеше 36 млн. сум тәшкил итте, узган ел дәрәҗәсенә карата үсеш 101,8%. Эшләүчеләр саны – 71 кеше, уртача хезмәт хакы - 11230 сум, үсеш 111,6%.

**Таблица № 8. Кулланучылар базары үсешенең көтелә торган күрсәткечләре**

| Күрсәткеч | Еллар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
| Ваклап сату әйләнеше, млн. сум | 1972,1 | 2086,0 | 2221,5 | 2368,1 | 2380,12 | 2499,13 |
| Халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтү күләме, млн. сум | 254,6 | 270,3 | 289,0 | 309,5 | 332,0 | 354,4 |

## 6. Социаль өлкәне үстерү

Базар икътисады урнашу шартларында кеше ресурсларының роле аеруча актуальләшә, аларны куллануны оптимизацияләү һәм үстерү алар белән нәтиҗәле идарә итүнең стратегик бурычларының берсе булып тора.Социаль өлкәне үстерү мөһим роль уйный, район һәм тулаем республика икътисадының киләчәге шуңа бәйле.

Социаль өлкәне үстерү кысаларында мөһим юнәлешләр булып түбәндәгеләр тора:

- халыкның белем һәм мәдәни дәрәҗәсен күтәрү;
- кеше ресурсларының инновацион активлыгын үстерү;
- халыкның һөнәри һәм социаль мобильлеге өчен шартлар тудыру;-
- районның социаль мохитен камилләштерү һәм үстерү юлы белән социаль яклангандыкны тәэмин итү;
- халыкның сәламәтлеген һәм сәламәтлек саклауның профилактик юнәлгәнлеген яхшырту.

Шулай итеп, өлкәнең социаль потенциалы муниципаль районның сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, халыкның мәшгульлеге һәм социаль ярдәм, физик культура һәм спорт кебек тармак системаларының үсеш дәрәҗәсе белән сыйфатлана.

### 6.1. Сәламәтлекне саклау

2018 ел нәтиҗәләре буенча ББМР сәламәтлек саклау учреждениеләренең республика рейтингында 4-5 урында тора, 5 ел элек 45 нче урында иде.

Эшкә яраклы яшьтән өлкәнрәк халык саны 33% тәшкил итә. Әйтергә кирәк, Балык Бистәсе районы демографик картлыкның югары дәрәҗәсе булган төбәккә кертелгән, шуңа күрә халыкның яшь структурасы демографик күрсәткечләргә йогынты ясый. Үлем-китем коэффициенты 1000 кешегә 16,4 тәшкил итә. 2018 елда 413 кеше вафат булды, бу 2017 елга караганда 7 кешегә кимрәк. Йөрәк-кан

тамырлары авыруларына каршы көрәш елы дип игълан ителгән 2018 ел дәвамында үзәк район хастаханәсе белгечләре тарафыннан берничә төрле профилактик чара үткәрелде.

Район үзәк хастаханәсе базасында сәламәтлек мәктәпләре оештырылган, аларда 400 гә якын кеше белем алган. Сырхауханә фойесында йөрәк-кан тамырлары авырулары темасы буенча белгечләрнең роликларын һәм лекцияләрен өзлексез трансляцияләү оештырылган, биналарның фасадында халык өчен артериаль кан басымы, кан шикәре, холестерин һәм авырлык нормалары турында мәгълүмат урнаштырылган растяжкалар эленгән.

2030 елга бурычлар:

- туучылар санын 1000 кешегә 9,5 кә кадәр җиткерү ;
- үлүчеләр санын 1000 кешегә 12,9 ка кадәр киметү;
- гомер озынлыгын 80 яшькә кадәр җиткерү.

*Балык Бистәсе районы буенча 2016 елдан 2018 елга кадәр динамикада халыкның табигый хәрәкәте коэффициентлары һәм 2030 елга көтелгән фараз күрсәткечләре (1 мең кешегә)*



*2016 елдан 2018 елга кадәрге чорда яман шешләрдән үлем-китем күрсәткече динамикасы һәм 2030 елга көтелгән фараз күрсәткечләре (100 мең кешегә)*




**Таблица 9. Социаль-икътисади үсешнең көтелә торган нәтиҗәләре**

| Исеме (атамасы) | 2016 ел | 2021 ел | 2030 ел |
|---|---|---|---|
| Гомуми үлем-китем | 16,4 | 14,2 | 12,9 |
| Сабыйлар үлеме | 6,0 | 5,2 | 4,3 |
| Туучылар саны | 6,7 | 8,0 | 8,5 |
| Яман шешләрдән үлем | 184,7 | 170,5 | 158,0 |
| Гомер озынлыгы | 74,7 | 75,5 | 80,0 |

**Сәламәтлек саклау өлкәсендәге проблемалар:**

1. Туучылар санының кимүе. 2018 елда районда 168 бала туган, бу 2017 елга караганда 5 балага кимрәк.

2. Аерым авырулардан үлем-китемнең күплеге: кан әйләнеше системасы авыруларыннан, шешләр барлыкка килүләрдән, туберкулездан һ. б.

3. Медицина кадрлары белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителмәгәнлек. Район буенча табиблар белән тәэмин ителеш 63% тәшкил итә. Нигездә тар профильле белгечләр җитми. 2018 елда 3 табиб эшкә алынды, алар барысы да торак белән (съёмный) тәэмин ителде.

4. Күрсәтелә торган медицина хезмәтләренең сыйфаты җитәрлек дәрәҗәдә югары булмау.

**Хәл итү юллары:**

Чирләрне иртә ачыклауны тәэмин итү һәм халыкны "Сәламәт булырга" мотивацияләү өлешендә профилактик эшне көчәйтү.

Халыкның аерым төркемнәрен диспансерлаштыру. Диспансерлаштыруны уздыруның сыйфатын күтәрү. Гомуми диспансерлаштыру мәгълүматларын киңрәк кулланырга, дәвалауның һәм диагностиканың эксперт бәяләүләре нигезендә халыктагы үлем-китемнең булдырмый калырдай сәбәпләрен ачыкларга, аны киметү буенча чаралар эшләргә.

Йогышлы булмаган хроник чирләр белән авыручыларны һәм аларның үсешенең югары куркынычы булган пациентларга тулы күләмдә диспансер күзәтүен оештыру һәм үткәрү.

Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау.

Районга медицина кадрларын җәлеп итү.

Матди-техник базаны ныгыту.

"Сәламәт яшәү рәвешенә бирелгәнлек формалаштыру" ведомствоара комитеты төзү.

"Сәламәтлекне саклау" һәм "Демография" милли проектларының индикатив күрсәткечләрен үтәү.

**Таблица № 10. Сәламәтлек саклауны үстерү өлкәсендәге чаралар**

| № | Чара | Үтәү сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Чирләрне иртә ачыклауны тәэмин итү һәм халыкны "Сәламәт булырга" мотивацияләү өлешендә профилактик эшне көчәйтү. | 2020-2030 еллар | ББМР БК, "Балык Бистәсе РҮХ" ДАССУ (килешенү буенча) | Агымдагы чыгымнар | ТР бюджеты |
| 2 | Халыкның аерым төркемнәрен диспансерлаштыру | 2020-2030 еллар | ББМР БК, "Балык Бистәсе РҮХ" ДАССУ (килешенү буенча) | Агымдагы чыгымнар | ТР бюджеты |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Диспансерлаштыруны уздыруның сыйфатын күтәрү. Гомуми диспансерлаштыру мәгълүматларын киңрәк файдаланырга, дәвалауның һәм диагностиканың эксперт бәяләүләре нигезендә халыктагы үлем-китемнең булдырмый калырдай сәбәпләрен ачыкларга, диспансеризация үткәрү буенча чаралар планын эшләргә һәм гамәлгә кертергә | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “Балык Бистәсе РҮХ” ДАССУ (килешенү буенча) | Агымдагы чыгымнар | ТР бюджеты |
| 4 | Йогышлы булмаган хроник чирләр белән авыручыларны һәм аларның үсешенең югары куркынычы булган пациентларга тулы күләмдә диспансер күзәтүен оештыру һәм үткәрү. | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “Балык Бистәсе РҮХ” ДАССУ (килешенү буенча) | Агымдагы чыгымнар | ТР бюджеты |
| 5 | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау. | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “Балык Бистәсе РҮХ” ДАССУ (килешенү буенча) | Агымдагы чыгымнар | ТР бюджеты |
| 6 | Районга медицина кадрларын җәлеп итү | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “Балык Бистәсе РҮХ” ДАССУ (килешенү буенча) | Агымдагы чыгымнар | ТР бюджеты |
| 7 | Матди-техник базаны ныгыту | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “Балык Бистәсе РҮХ” ДАССУ (килешенү буенча) | Агымдагы чыгымнар | ТР бюджеты |
| 8 | “Сәламәт яшәү рәвешенә бирелгәнлек формалаштыру” ведомствоара комитеты төзү. | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “Балык Бистәсе РҮХ” ДАССУ (килешенү буенча) | Агымдагы чыгымнар | - |
| 9 | “Сәламәтлекне саклау” һәм “Демография” милли проектларының индикатив күрсәткечләрен үтәү. | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “Балык Бистәсе РҮХ” ДАССУ (килешенү буенча) | Агымдагы чыгымнар | - |

## 6.2 Мәгариф

Районда мәгариф өлкәсендә 6 төп мәктәп, 8 урта мәктәп, мәктәпкәчә төркем белән 2 төп мәктәп, мәктәпкәчә төркем белән 4 урта мәктәп, 1 гимназия, 3 өстәмә белем бирү оешмасы һәм 14 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы хезмәт күрсәтә. Район үзәге буенча сыйныфларның тулылануы 19,1 кеше тәшкил итә, ә норматив буенча 25 кеше булырга тиеш, авыл мәктәпләрендә сыйныфларның тулылануы 5,8 кеше (норматив 14 кеше) тәшкил итә, район буенча сыйныфка уртача 8,5 бала туры килә. 2019 елда мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү системасында үзгәрешләр күп булды.

Ике мәҗбүри фән буенча БДИ нәтиҗәләре район белем бирү оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген билгеләүче төп индикатор булып тора. Рус теле буенча уртача балл 71,26 (республика 74,25), математика буенча 58,67 (республика 64,43) тәшкил итте.

Үткән елда 9 һәм 11 сыйныфларны тәмамлаучылар барысы да белем турында аттестат алдылар. 115 чыгарылыш сыйныф укучысы арасыннан - 20 медалист.

2018-2019 уку елында 1 педагог "Оста мөгаллим" грантына лаек булды.

Район буенча балаларны өстәмә белем бирүгә тарту 86,2% тәшкил итә. Озак еллар нәтиҗәле хезмәте, халыкара, бөтенроссия, төбәкара, республика конкурсларында һәм чараларда җиңүләре һәм призлы урыннар яулаганы өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы (№ под-1698/18, 19.11.2018) белән “Рапсодия” коллективына “Үрнәк балалар хореография коллективы” исеме бирелде. “Балалар иҗат үзәге” өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе техник иҗат үсешенә грант отты.

Районда тәрбиягә бала алган һәм химаяче гаиләләр белән планлы эш оештырылган: районның төрле хезмәтләр вәкилләре белән түгәрәк өстәлләр, тәрбиягә бала алган ата-аналар җыелышлары. Бүгенге көндә 60 бала 15 тәрбиягә бала алган һәм 26 химаяче гаиләсендә тәрбияләнә.

**Мәгариф өлкәсендәге максат** – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы халкының гарызнамәләре нигезендә белем бирүнең югары сыйфатын тәэмин итү.

**Бурычлар:**

мәктәпкәчә яшьтәге балаларны һәрьяклап үстерү һәм мәктәптә укытуга әзерләү;

гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры китереп һәркем өчен мөмкин булган сыйфатлы гомуми белем алу гарантияләрен тәэмин итү;

мөмкинлекләре чикләнгән балаларга инклюзив белем бирү өчен шартлар тудыру;

сәләтле балаларны ачыклау һәм аларга булышулы озата бару системасын булдыру;

белем бирүнең заманча формаларын үстерү хисабына , профильле укытуны да кертеп, югары дәрәҗәдәге индивидуальләштерүне тәэмин итү;

яшь педагогик кадрларны җәлеп итү һәм аларның һөнәри үсеше;

яңа белем бирү технологияләрен һәм уку процессын оештыру принципларын, шул исәптән заманча мәгълүмати һәм коммуникацион технологияләр кулланып, гамәлгә кертү.

**Өстенлекле юнәлешләр:**

- Мәктәпкәчә белем бирү;
- Гомуми (мәктәп) белем бирү;
- Өстәмә белем бирү.

**Мәгариф өлкәсендәге проблемалар:**

- балаларга белем бирү оешмаларында (балалар бакчаларында) урыннар белән җитәрлек тәэмин ителмәү;
- квалификацияле кадрлар кытлыгы, яшь педагогларны авыл мәктәпләренә җәлеп итү проблемасы кискен тора;

- яшьләрнең авыл җирләреннән китүе авыл халкының азаюына сәбәпче, бу, үз чиратында, мәктәпләрне, мәктәпкәчә мәгариф оешмаларын аз комплектлы мәгариф оешмаларына үзгәртеп коруга китерә;

- аз комплектлы авыл мәктәпләренең башлангыч сыйныфларында укыту һәм тәрбия бирүнең нәтиҗәлелеге кимү;

- белем бирү оешмаларында мөмкинлекләре чикләнгән балаларга инклюзив белем алу өчен шартлар тудыру зарурлыгы;

- балаларның мәдәни һәм социаль үсеше өчен мөмкинлекләре җитәрлек булмаган һәм индивидуаль булышулы озата баруга мохтаҗ гаиләләр саны арту;

-районда һөнәри белем бирү оешмасын саклап калу зарурлыгы.

**Проблемаларны хәл итү юллары һәм гамәлләр юнәлеше:**

Мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларын тормышка ашыру;

Белем бирүнең сыйфатын бәяләү системасын кертү;

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларга, инвалид балаларга гомуми белем алу өчен шартлар тәэмин итү;

Укучыларны тулысынча сыйфатлы тукландыру өчен шартлар тәэмин итү;

Мәктәпләрдә иң яхшы педагогларны саклап калу, яшь белгечләрне җәлеп итү өчен мораль һәм матди стимуллар системасын булдыру;

Хезмәт базарын, чыгарылыш укучылары тарафыннан булачак һөнәрен сайлауны исәпкә алып укучыларга укыту планын сайлау мөмкинлеген тәэмин итә торган профильалды һәм профильле укыту кертүне дәвам итү;

Автобус паркын яңарту һәм тулыландыру (14 берәмлек кирәк);

Балаларга өстәмә белем бирү оешмалары эшчәнлеген стимуллаштыру системасын булдыру;

Район психологик-педагогик хезмәте булдыру;

Дәрестән тыш һәм мәктәптән тыш эшчәнлекнең төрле формаларына тартылган балалар һәм яшүсмерләр санын арттыру.

**Таблица № 11. Мәгарифне үстерү өлкәсендәге чаралар**

| № | Чара | Үтәү сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларын тормышка ашыру | 2019-2030 еллар | ББМР БК, “БК Мәгариф бүлеге” МКУ (килешенү буенча) | Агымдагы финанслау | ТР бюджеты |
| 2 | Белем бирүнең сыйфатын бәяләү системасын кертү | 2019-2030 еллар | ББМР БК, “БК Мәгариф бүлеге” МКУ (килешенү буенча) | Агымдагы финанслау | ТР бюджеты |
| 3 | Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларга, инвалид балаларга гомуми белем алу өчен шартлар тәэмин итү | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “БК Мәгариф бүлеге” МКУ (килешенү буенча) | Агымдагы финанслау | ТР бюджеты |
| 4 | Укучыларны сыйфатлы тукландыру өчен шартлар тәэмин итү | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “БК Мәгариф бүлеге” МКУ (килешенү буенча) | 4 381,45 | ТР бюджеты |
| 5 | Мәктәпләрдә иң яхшы педагогларны саклап калу, яшь белгечләрне җәлеп итү өчен мораль һәм матди стимуллар системасын булдыру | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “БК Мәгариф бүлеге” МКУ (килешенү буенча) | Агымдагы финанслау | ТР бюджеты |
| 6 | Хезмәт базарын, чыгарылыш укучылары тарафыннан булачак һөнәрен сайлауны исәпкә алып укучыларга укыту планын сайлау мөмкинлеген тәэмин итә торган профильалды һәм профильле укыту кертүне дәвам итү | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “БК Мәгариф бүлеге” МКУ (килешенү буенча) | Агымдагы финанслау | ТР бюджеты |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 7 | Автобус паркын яңарту һәм тулыландыру (14 берәмлеккә) | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “БК Мәгариф бүлеге” МКУ (килешенү буенча) | 30 000,0 | ТР бюджеты |
| 8 | Район психологик-педагогик хезмәте булдыру | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “БК Мәгариф бүлеге” МКУ (килешенү буенча) | 1 460,0 | ТР бюджеты, җирле бюджет |
| 9 | Балаларга өстәмә белем бирү оешмалары эшчәнлеген стимуллаштыру системасын булдыру | 2020-2021 еллар | ББМР БК, “БК Мәгариф бүлеге” МКУ (килешенү буенча) | Агымдагы финанслау | ТР бюджеты |
| 10 | “Күгәрчен гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә һәм “Дуслык” Котлы Бөкәш балалар бакчасында капиталь ремонт үткәрү | 2020 ел | ББМР БК, “БК Мәгариф бүлеге” МКУ (килешенү буенча) | 16 643,17 | ТР бюджеты , җирле бюджет |
| 11 | Дәрестән тыш һәм мәктәптән тыш эшчәнлекнең төрле формаларына тартылган балалар һәм яшүсмерләр санын арттыру | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “БК Мәгариф бүлеге” МКУ (килешенү буенча) | Агымдагы финанслау | ТР бюджеты |

**6.3 Мәдәният**

Балык Бистәсе муниципаль районы мәдәният өлкәсендә мәдәни мирасны саклау, традицион сәнгать юнәлешләрен үстерү, яңа технологияләр кертү, гражданнар өчен сәнгати кыйммәтләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү һәм аларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар гамәлгә ашырыла.

Милли проектлар кысаларында үткәрелә торган чаралар һәм Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән башкарылучы авыл клубларын төзү һәм реконструкцияләү буенча республика программалары мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын, аларны техник яктан яңадан җиһазлауны модернизацияләр.

“2009-2014 елларга һәм перспективадагы 2020 елга кадәр Татарстан Республикасында китапханә эшен үстерү” озак сроклы максатчан программасы нәтиҗәләре буенча Балык Бистәсе муниципаль районының барлык китапханәләре компьютер техникасы белән җиһазландырылды һәм республиканың һәм районның җыелма электрон каталогында эшли. Бу китапханәдән файдаланучыларга мәгълүмати хезмәтләр күрсәтеп, сыйфатлы яңа дәрәҗәдә хезмәт күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Безнең район белән Татарстан Республикасының күп кенә мәдәният эшлеклеләре язмышы бәйле: Шәрәфиев Равил Шиһабетдин улы - Г.Камал исемендәге театр актеры, Шиһапов Мансур Әхмәт улы - шагыйрь һәм композитор, Фәйзуллин Равил Габдрахман улы - Татарстан Республикасының халык шагыйре, Җәләлов Хәлим Бәдретдин улы - Г.Камал исемендәге театр актеры, Нуруллин Вәкыйф Нурулла улы - язучы, Әхмәтҗанов Роберт - язучы, Хәйретдинова Роза Котдус кызы - Татарстан Республикасының халык, Россия Федерациясенең атказанган артисты, Гаффаров Әхәт Габдрахман улы - язучы, Сафиуллин Әхәт Хафизулла улы - язучы, Гомәров Госман Гомәр улы – язучы, Нәҗмиев Нуретдин Гыйльмехан улы - К.Тинчурин исемендәге театр актеры.

Мәдәниятне үстерү өчен районның потенциалы зур һәм Балык Бистәсе муниципаль районының мәдәният учреждениеләре челтәре 88 учреждениене берләштерә. Шуларның 1 се - район Мәдәният йорты, 31 е – авыл мәдәният йортлары, 14 клуб, 38 китапханә, 3 музей һәм 1 автоклуб.

Мәдәният өлкәсендә 275 кеше эшли, шуларның 157 белгече төп персоналга карый, шуларның 6 сы югары профильле белемгә ия, урта махсус (профильле) белемле - 60 кеше.

Халыкның ялын оештыру һәм халык иҗатын үстерү өчен районның клуб учреждениеләрендә 238 берләшмә эшли, аларда 2728 кеше ял итә, шуларның 14 яшькә кадәрге балалар өчен – 67 се, аларда 729 бала, 15 яшьтән алып 25 яшькә кадәрге яшүсмерләр һәм яшьләр өчен 52 се, аларда 577 кеше шөгыльләнә.

6434 мәдәни-гаммәви чара уздырылган, шул ук вакытта 2019 елның 9 аенда 1 клубка уртача 140 чара туры килә. Мәдәни-ял итү чараларының гомуми санының 997 се - 14 яшькә кадәрге балалар өчен, 4380 е -15 яшьтән 24 яшькә кадәрге яшьләр өчен. 324 чара түләүле нигездә үткәрелде. Аларда 11705 кеше булды.

**Районда 7 халык коллективы үз эшен алып бара:**

- район мәдәният йортының "Калинушка" ветераннарның рус халык хоры,
- район мәдәният йортының "Өмет" халык фольклор коллективы,
-район мәдәният йортының "Чулман моңнары" гармунчылар коллективы,
-район мәдәният йортының халык театры,
- РДКның "Камские зори" халык вокаль ансамбле,
-Кызыл Йолдыз авыл мәдәният йортының "Чулпы" халык фольклор коллективы,
-Казак Чаллысы авыл мәдәният йортының "Нур" халык фольклор коллективы.

2011 елдан алганда клуб тибындагы 9 мәдәният учреждениесе төзелгән.

**Программадан тыш:**

Яңа Арыш авыл мәдәният йорты - 2011 ел.

**Иганәче хисабына:**

Бикчурай мәдәният йорты - 2013 ел.

**"Авыл клублары" Республика программасы буенча (7):**

Олы Салтан авыл мәдәният йорты - (2012 ел), 212 урынга исәпләнгән;

Ямаш авыл мәдәният йорты - (2013 ел), 200 урынга исәпләнгән;

Югары Тегермәнлек мәдәният йорты - (2014 ел), 200 урынга исәпләнгән;

Район мәдәният йорты - (2015 ел), 350 урынга исәпләнгән;

Тәберде Чаллысы мәдәният йорты - (2016 ел), 50 урынга исәпләнгән;

Корноухово авыл мәдәният йорты - (2017 ел), 50 урынга исәпләнгән;

Күки авыл мәдәният йорты - (2018 ел), 100 урынга исәпләнгән.

Балык Бистәсе районында мәдәният өлкәсе үсешенә ныклы нигез салынган, аның **көчле яклары:**

Тарихи-мәдәни мирасның уникальлеге һәм үзенчәлекле булуы ("XII-XVI йөзләрдәге Чаллы (Тәберде) шәһәрлеге" тарихи-мәдәни территориясе).

Район халкының бай традицияләре һәм үзенчәлеге.

Район җирлекләре арасындагы милләтара, динара һәм мәдәниятара багланышларның югары дәрәҗәсе.

Муниципаль район байлыгы - иҗади талантлар. Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә күренекле эшлеклеләрнең булуы.

Муниципаль район территориясендә мәдәни инфраструктура челтәре булу.

Мәдәният эшчәнлегенә анализ аның үсешенең йомшак якларын да күрсәтте:

мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасы йомшак, аның заманча стандартларга һәм халыкка хезмәт күрсәтү нормаларына туры килмәве.

Музыкаль инструментлар һәм кыйммәтле аппаратура сатып алуга җитәрлек финанс кертемнәре булмау.

Социаль-мәдәни өлкәдә проблемаларны хәл итүнең заманча дәрәҗәсенә кадрлар потенциалының туры килмәве (кадрлар составының картаюы).

Районның мәдәни-ял итү учреждениеләрендә бердәм мәгълүмати-техник инфраструктура булмау.

Нәтиҗәсе: виртуаль киңлектә югары хәбәрдарлык-мәгълүматлылыкны, аралашу, диалог һәм мәдәният ресурсларыннан һәркем өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итә торган коммуникацион каналларның үсмәве.

Мәдәни туризм инфраструктурасы үсмәгән һәм кунакчыллык традицияләре актуальләшмәгән.

Авыл территорияләренең мәдәни брендларын алга этәрүнең начар булуы.

Район мәдәният учреждениеләренең янгын сүндерү һәм саклау нормаларына туры килмәве.

Әлеге проблемаларны хәл итү өчен глобаль көндәшлектә уңышка ирешүнең ачкычы буларак хәзерге заман икътисадының нигезе булып кеше капиталы танылган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисади үстерү Стратегиясе нигезендә Балык Бистәсе муниципаль районы мәдәниятен саклап калуның, аңа ярдәм итүнең һәм үстерүнең яңа механизмнарын булдыруга һәм гамәлдәгеләренең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлтелгән чаралар комплексы кирәк.

**Максатлар:**

Мәдәният хезмәтләренең күптөрлелеге һәм аларның югары сыйфатын тәэмин итү хисабына Балык Бистәсе муниципаль районының мәдәни мирасын һәм традицияләрен саклап калуны, һәрбер кешенең яшәү урынына һәм керем дәрәҗәсенә бәйсез рәвештә мәдәни тормышта катнашу һәм үзенең иҗади үсеше өчен мөмкинлекләрен тәэмин итүче үзенә тартып тора, җәлеп итә торган мәдәни мохит булдыру.

**Бурычлар:**

- Мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту, музыка кораллары, яктылык-тавыш техникасы һәм заманча дәрәҗәдә чаралар үткәрүне тәэмин итүгә мөмкинлек бирүче махсус җиһазлар сатып алу.

- Югары мәгълүматлылыкны, аралашуны, диалогны һәм виртуаль киңлектә мәдәният ресурсларына һәркемгә керүне тәэмин итүче район халкының мәдәни традицияләрен һәм рухи-әхлакый кыйммәтләрен торгызуга юнәлеш тоткан бердәм цифрлы мәдәни киңлек формалаштыру.

- Балык Бистәсе муниципаль районында яшәүчеләрнең мәгълүмати культурасын формалаштыру, мәгълүмати-коммуникация технологияләрен куллануга кызыксынуны стимуллаштыру.

- Китапханә һәм музей фондлары ресурсларын туплауны (тулыландыруны), саклауны, актуальләштерүне һәм халыкка файдалану мөмкинлеген тәэмин итә торган мәдәният учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү.

- Яңа төзелгән һәм ремонтланган клуб учреждениеләрен инновацион үстерүне һәм алардан нәтиҗәле файдалануны тәэмин итә торган социаль-мәдәни кластерлар булдыру, яңа икътисади мөнәсәбәтләр булдыру һәм мәдәният һәм туризм өлкәсе кооперациясен үстерү.

- Районның социаль-мәдәни кластерларын булдыру нигезендә мәдәни туризм һәм территорияләрнең авыл брендлары маршрутларының киң спектрын булдыру һәм алга җибәрү, ә бу районның мәдәни мирасын нәтиҗәле файдалануга китерәчәк.

**Тормышка ашыру:**

Балык Бистәсе муниципаль районы тарихи-мәдәни мирас үзенчәлегеннән тыш тагын табигый-ландшафт ресурсы һәм район халкының үзенчәлеге белән дә бай.

Район территориясе Татарстан Республикасы үзәгендә урнашкан һәм 2030 ел Стратегиясе буенча Казан икътисади зонасына керә. Район федераль һәм төбәкара коридорлар киселешендә һәм “Идел-Чулман агымы” экозона үзәгендә урнашкан.






Мәдәни туризм өлкәсендә районның җәлеп итүчәнлеге югары. Безнең территориядә татар, рус һәм татар халкының керәшен кардәшләре мәдәнияте үсеш алган. Әлеге территорияләр берничә билге буенча социаль-мәдәни кластерларга җиңел оеша:



- Кластер урнашкан территорияләр Балык Бистәсе районының төп юллары белән туры килә.

- Районда эшләнгән туристлык маршрутлары белән туры киләләр.

-Аерым функциональ тармак ярдәмче системаларны (мәдәният йорты, китапханә, музей) оештырылган системага (перспективада хезмәт күрсәтүләрнең гомуми комплексы) берләштерәләр.

- Эшчәнлеге нәкъ менә шушы территорияләрне үстерүгә юнәлдерелгән район инвесторлары белән хезмәттәшлек итү мөмкинлеге бар. ("Кулон Агро" ҖЧҖ, “Дикая ферма "КФХ," Круг " ҖЧҖ, “Русский мрамор”АПК).

– Кече бизнес вәкилләре белән хезмәттәшлек итү мөмкинлеге бар (чәчтарашханә, фото-видео сервис, балалар кафесы, сувенир кибете, халык йолаларын билгеләү, никахларны, алтын һәм көмеш юбилейларны тантаналы теркәү, авыл туризмын үстерү).

- Кызыклы мәдәни мохит булдыру аша көндәшлеккә сәләтле иҗади кластер төзелә.

Социаль-мәдәни кластерлар булдыру Балык Бистәсе районының һәр торак пунктында халыкның мәдәни һәм иҗат эшчәнлеге өчен кирәкле минималь һәм җитәрлек шартлар һәм ресурсларны тәгаенләп мәдәни мохит булдыру бурычын тулысынча хәл итәргә тиеш.

Кластерларны үстерү өчен матди-техник база һәм бердәм цифрлы мәдәни киңлек, китапханә һәм музей эшен үстерү кирәк.

Авыл җирлекләре базасында нәкъ менә социаль-мәдәни кластерлар булдыру Балык Бистәсе районында яшәүчеләрнең иҗади потенциалының яңа үсешенә этәргеч (борылышы) булырга мөмкин.

# Таблица № 12. Мәдәниятне үстерү өлкәсендәге чаралар

| № | Чара | Үтәү срокла ры | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогында 400 урынга исәпләнгән Мәдәният йорты төзү | 2024 ел | ББМР БК, "Социаль-мәдәни өлкә бүлеге" МКУ(килешенү буенча) | 60000,0 | ТР бюджеты, җирле бюджет |
| 2 | Биектау авылында 200 урынга күпфункцияле үзәк (КФҮ) төзү | 2020 ел | ББМР БК, "Социаль-мәдәни өлкә бүлеге" МКУ(килешенү буенча) | - | ТР бюджеты, җирле бюджет |
| 3 | Төзелеш:<br>Алан-Полян мәдәният йорты 50 урынга<br>Бирдебәк мәдәният йорты 50 урынга<br>Шестая Речка мәдәният йорты 50 урынга | 2022 ел<br>2024 ел<br>2023 ел | ББМР БК, "Социаль-мәдәни өлкә бүлеге" МКУ(килешенү буенча) | 6000,0<br>6000,0<br>6000,0 | ТР бюджеты, җирле бюджет |
| 4 | Мәдәният объектларына капиталь ремонт:<br>-Котлы Бөкәш мәдәният йорты<br>- Олы Елга мәдәният йорты<br>-Масловка мәдәният йорты<br>-Зур Мәшләк мәдәният йорты<br>-Анатыш мәдәният йорты<br>-Казак Чаллысы мәдәният йорты<br>-Үзәк китапханә | 2020 ел<br>2021 ел<br>2022 ел<br>2023 ел<br>2021ел<br>2022 ел<br>2022 ел | ББМР БК, "Социаль-мәдәни өлкә бүлеге" МКУ(килешенү буенча) | 3 900,0<br>17 700,0<br>32 000,0<br>6 000,0<br>9 600,0<br>17 500,0 | ТР бюджеты, җирле бюджет |
| 5 | Мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту:<br>музыкаль инструментлар сатып алу;<br>яктылык-тавыш техникасы җиһазлары;<br>-сәхнә костюмнары | 2020-2030 еллар | ББМР БК, "Социаль-мәдәни өлкә бүлеге" МКУ(килешенү буенча) | 1380,00<br><br>920,00<br>1000,00 | ТР бюджеты, җирле бюджет |
| 6 | Районның мәдәни-ял итү учреждениеләренең мәгълүмат-технологик инфраструктурасын булдыру:<br>- компьютер җиһазлары сатып алу;<br>- Интернет челтәренә тоташтыру;<br>- Wi-Fi тоташтыру; | 2020-2030 еллар | ББМР БК, "Социаль-мәдәни өлкә бүлеге" МКУ(килешенү буенча) | 1350,00<br><br>230,00 | ТР бюджеты |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 7 | Санлы мәгълүмат ресурсларын булдыру һәм алардан файдалану өлкәсендә мәдәният учреждениеләре белгечләренең компьютер белән эшләүдә компетентлыкларын күтәрү | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “Социаль-мәдәни өлкә бүлеге” МКУ(килешенү буенча), ”Мәгариф бүлеге” МКУ (килешенү буенча) | 145,00 | Җирле бюджет |
| 8 | Район территориясендә өч социаль-мәдәни кластер булдыру | 2021-2030 еллар | ББМР БК, “Социаль-мәдәни өлкә бүлеге” МКУ(килешенү буенча) | Бюджеттан тыш керемнәр һәм чыганаклар | Инвесторларның иганәчелек ярдәме |
| 9 | Район мәдәният учреждениеләренең янгын сүндерү һәм саклау нормаларына туры килмәвен бетерү.<br>- ашыгыч чакыру төймәсе урнаштыру<br>- янгын сүндерү сигнализациясе урнаштыру<br>- янгын сүндерү һәм саклау җиһазларына техник хезмәт күрсәтү | 2020-2025 еллар | ББМР БК, “Социаль-мәдәни өлкә бүлеге” МКУ(килешенү буенча),җирле үзидарә органнары | 6 900,00 | ТР бюджеты, җирле бюджет |

### 6.4. Спорт

Районның спорт тормышы гаять бай. “Спорт мәктәбе” МБУнең 6 спорт бүлекчәсе, 1000гә якын бала һәм яшүсмерне үзенә тартып, Балалар сәламәтләндерү-белем бирү үзәгенең 40 төркеме 12 спорт төре буенча эшен алып бара.

Безнең көрәшчеләр Хәйриев Данил, Закиров Илсаф, Пулатов Марат, Гыйльмуханов Дилүс, футболчылар командасы үз уңышлары белән традицион рәвештә куандыра. Район милли көрәш буенча республика рейтингында 17 урынны һәм яшьләр сәясәте буенча 37 урынны били.

Алкалы хоккей, футбол, йөзү, милли көрәш, массакүләм чаңгы ярышлары район күләмендә күп катнашучылар катнашында киң колач белән уза.

Районда спорт белән шөгыльләнү өчен менә дигән база бар - футбол стадионы, йөзү бассейны булган спорт комплексы, 20 хоккей тартмасы, шулардан 6 сы – “Татнефть” ААҖ бүләк иткән заманча пластик мәйданчык, 14 универсаль спорт мәйданчыгы һәм 23 спорт залы. Бездә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче халыкның тоткан урынын 2030 елга 49,9 %тан 63 %ка җиткерергә барлык нигезләр дә бар.

ББМРда физик культураны һәм спортны үстерү алып барыла торган социаль сәясәтнең өстенлекле юнәлеше булып тора һәм норматив-хокукый нигезгә нигезләнә. Физик культура һәм спортны үстерү өчен киң мөмкинлекләр булдырыла.

2020-2021 елларга физик культураны һәм спортны үстерүнең максатлары булып физик культураны, спортны үстерү, аларны район халкының сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруда куллану, физкультура-савыктыру һәм спорт эшен үстерүдә катнашучы барлык учреждениеләр һәм иҗтимагый оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру тора.

**Спортны үстерү бурычлары:**

- яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен һәм яшьләр арасында сәламәтлекне ныгыту һәм саклау буенча тиешле күнекмәләр формалаштыру;
- матди-спорт базасын камилләштерү;
- физкультура кадрларының һөнәри осталыгын күтәрү;
- физик тәрбия һәм спорт әзерлеге буенча инновацион технологияләр эшләү.

Районда физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүнең киңрәк таралуын көчәйтү буенча билгеле бер күләмдә эш алып барыла.

2019 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында массакүләм физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр саны 12011 кеше тәшкил итте, бу - район халкының гомуми санының 49,9 проценты дигән сүз.

Сәламәтләндерү һәм спорт-массакүләм эшне оештыру 2975 кешене үз эченә алган 3 физкультура коллективында алып барыла. Соңгы елларда Татарстанда төрле милек формасындагы предприятиеләрдә физкультура-спорт эше активлашты. Республиканың төрле финал спорт ярышларында ел саен ике меңнән артык хезмәткәр катнаша. Физкультура-спорт активлыгын күтәрү, хезмәткә яраклы халык арасында сәламәт яшәү рәвеше белән кызыксынуны арттыру, җитештерүдәге физкультура коллективларының санын арттыру республика физкультура-спорт җәмгыятьләре һәм профсоюзларның тармак рескомнары арасында хезмәттәшлек турында озак сроклы килешүләр төзүдән соң мөмкин булды. Гаммәви физкультура-спорт чаралары уздыру халыкны сәламәт яшәү рәвешенә җәлеп итүнең бер формасы булып тора.

Мәсәлән, “Россия чаңгы юллары” Бөтенроссия чаңгы ярышлары һәм “Милләт кроссы” Бөтенроссия йөгерү көне кысаларында районыбызда “Татарстан чаңгы юлы” гаммәви чаңгы ярышлары һәм ел саен 2000 гә якын кеше катнашкан җиңел атлетика ярышлары уздырыла.

Авыл халкын физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү максатларында республикада ел саен “Сәламәтлек” комплекслы чарасы уздырыла, анда ел саен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында яшәүче 9000гә кадәр кеше катнаша. “Көрәш” милли спорт көрәше буенча ярышлар халык арасында аеруча популяр, аларда яшь егетләр һәм өлкәннәр арасында район җыелма командалары катнаша.

“2018 елның 31 декабренә торышы буенча Татарстан Республикасында адаптив физик культура һәм спорт турында мәгълүматлар” 3-АФК еллык статистик хисап мәглүматлары буенча Татарстан Республикасында халыкның 8,1% ы адаптив физик культура һәм спорт белән шөгыльләнә. Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне җәлеп итү, аларны социаль адаптацияләү максатыннан район халкы ел саен республика инвалидлар физкультура-спорт җәмгыяте, яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге тарафыннан оештырылган республика ярышларында катнашалар, инвалидлар арасында агитация

узышы оештырыла. Физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында ел саен 5 спорт төре буенча ярышлар үткәрелә.

Районда физик культура һәм спорт өлкәсендә ББМР "Спорт мәктәбе" муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе, ББМР "Балалар сәламәтләндерү- белем бирү (профильле) үзәге" муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе, ББМР "Дельфин" спорт-сәламәтләндерү комплексы муниципаль бюджет учреждениесе эшли.

"Спорт мәктәбе" МБУдә спорт белән шөгыльләнүче укучыларның гомуми саны 486 кеше, "БСББ(П)Ү" ӨББ МБУ линиясе буенча 493 укучы тәшкил итә. "Спорт мәктәбе" МБУ, "БСББ(П)Ү" ӨББ МБУ тренерлары тарафыннан укыту-тренировка дәресләре "Дельфин" спорт-сәламәтләндерү комплексы һәм "Спорт мәктәбе" МБУнең структур бүлекчәсе "Яшьлек" стадион-мәйданчыгы базасында, шулай ук район җирлекләренең спорт залларында алып барыла.

"Дельфин" спорт-сәламәтләндерү комплексында 2 йөзү бассейны, фитнес белән шөгыльләнү өчен кече һәм зур зал, милли көрәш белән шөгыльләнү өчен зал, спортның уен төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт залы, сауна, тренажер залы, массаж кабинеты, гидромассаж кабинеты, җылы киенү-чишенү бүлмәләре булган пластик хоккей тартмасы бар.

Физик культураны һәм спортны пропагандалау өчен яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек тарафыннан гаммәви мәгълүмат чараларын агымдагы ярышлар һәм район һәм республика ярышларында иң көчле спортчыларның чыгышлары буенча материаллар белән оператив тәэмин итү системасы эшләнде.

Шулай ук Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-сайты даими рәвештә фото һәм видео материаллары булган яңа спорт мәгълүматы белән тулыландырыла. Барлык спорт чаралары гаммәви мәгълүмат чараларында, шул исәптән "Авыл офыклары" («Сельские горизонты») район газетасында да яктыртыла.

**Спорт өлкәсендәге проблемалар:**

-физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче халыкның өлеше зур түгел;

- авыл торак пунктларында хоккей тартмалары, спорт мәйданчыклары төзү өчен җирле бюджетта акча җитмәү.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, 2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында физик культура һәм спорт үсешенең түбәндәге төп юнәлешләрен формалаштырырга мөмкин:

1. сәламәтлекне актив саклау һәм ныгыту, сәламәтлек культурасы дәрәҗәсен һәм потенциалын күтәрү, вакытыннан алда килүче үлем-китемне кисәтү, уртача гомер озынлыгын һәм халыкның тормыш сыйфатын арттыру;

2. халыкның сәламәтлеген ныгыту буенча чараларда катнашуга мотивация тудыру, шәхси белемнәрен һәм сәламәт яшәү рәвешенең индивидуаль осталык һәм күнекмәләрен үстерү;

3. районның спорт оешмаларын һәм учреждениеләрен массакүләм физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт занятиеләрендә катнашуга һәм уздыруга актив җәлеп итү;

4. авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына уен мәйданчыклары, хоккей тартмалары, инвентарь белән тәэмин итүдә ярдәм итү;

5. мәктәп һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларга физик тәрбия бирү сыйфатын яхшырту;

6. эшләүче яшьләр, хезмәткәр һәм тулаем алганда районыбыз яшьләре арасында спорт-савыктыру чараларын оештыру һәм уздыру;

7. сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру һәм социаль-негатив күренешләрне профилактикалау максатларында “Форпост” җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр берләшмәсе эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

8. массакүләм физик культураны, спортны һәм туризмны үстерү. Хоккей тартмалары төзү, спорт җиһазлары алу.

9. физик культура һәм спорт өлкәсенә өстәмә ресурслар, иганәчелек чараларын җәлеп итү өчен шартлар тудыру;

10.”Хезмәткә һәм оборонага әзер” (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәгән район гражданнарының өлешен арттыру.

**Көтелә торган нәтиҗәләр:**

- тәэмин итүнең норматив дәрәҗәсенә туры китереп, 2021 елга спорт инфраструктурасын формалаштыру, поселокта һәм районда яшәү урыны буенча физкультура эшен оештыру ;

- район халкының төп өлешен физкультура секцияләренә тарту;

-физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче халыкның тоткан урынын күтәрү, “Хезмәткә һәм оборонага әзер” (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәгән район халкының өлешен арттыру.

-физкультура хезмәтләренең аеруча кирәкле төрләренең (йөзү бассейны, тренажёр залы, фитнес клубы) үз чыгымнарын үзләре каплауга күчүен гамәлгә ашыру.

**Хәл итү юллары:**

Сәламәтлекне актив саклау һәм ныгыту, сәламәтлек культурасы дәрәҗәсен һәм потенциалын күтәрү, вакытыннан алда килүче үлем-китемне кисәтү, уртача гомер озынлыгын һәм халык тормышының сыйфатын арттыру.

Халыкның сәламәтлеген ныгыту буенча чараларда катнашуга мотивация тудыру, сәламәт яшәү рәвешенең индивидуаль осталык һәм күнекмәләрен үстерү.

Районның спорт оешмаларын һәм учреждениеләрен массакүләм физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт занятиеләрен уздыруга һәм аларда катнашуга актив җәлеп итү.

Авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына уен мәйданчыклары, хоккей тартмалары, инвентарь белән тәэмин итүдә булышу;

Мәктәп һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларга физик тәрбия бирү сыйфатын күтәрү.

Эшләүче яшьләр, хезмәткәрләр һәм тулаем алганда районыбыз яшьләре арасында спорт-сәламәтләндерү чараларын оештыру һәм уздыру.

Сәламәт яшәү рәвеше булдыру һәм социаль-негатив күренешләрне профилактикалау максатларында “Форпост” җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр берләшмәсе эшчәнлеген гамәлгә ашыру.

Физик культура һәм спорт өлкәсенә өстәмә ресурслар, иганәчелек чараларын җәлеп итү өчен шартлар тудыру.

“Хезмәткә һәм оборонага әзер” (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәгән район гражданнарының өлешен арттыру.

Универсаль спорт мәйданчыклары төзү һәм реконструкцияләү.

Хоккей тартмалары төзү, спорт җиһазлары алу, спорт корылмаларын ел әйләнәсендә файдалану.

Ябык боз сарае төзү.

Блоклы модульле чаңгы базасы төзү.

Балык Бистәсе районы территориясендә “Өченче яшь” Спартакиадасы кысаларында халыкның урта һәм өлкән яшьтәге төркемнәре (ветераннар, олы яшьтәге кешеләр) арасында район, зона һәм республика физкультура-савыктыру, комплекслы, спорт чаралары уздыру һәм күрсәтелгән категориянең аларда катнашуы.

“Сәламәтлек”, “Авыл Яшьлере”, “Спорт төрләре буенча муниципаль хезмәткәрләр спартакиадасы” кысаларында авыл районнары командалары арасында чемпионатлар, беренчелекләр, ачык турнирлар, комплекслы чаралар үткәрү.

Гомуми белем бирү оешмаларында спортның уен төрләрен үстерү, шул исәптән “КЭС-БАСКЕТТ” мәктәп баскетбол лигасы ярышларын үткәрү; “Мини-футбол - мәктәпкә!” гомумроссия проектын гамәлгә ашыру кысаларында мини-футбол буенча. “Президент бәйгеләре” ярышларында һәм фестивалендә катнашу “Президент спорт уеннары” ярышлары. Популяр спорт-гаммәви чаралар (“Милләтләр кроссы”, “Россия чаңгы юлы”, “Бөек Ватан сугышында Җиңүнең еллыгын бәйрәм итүгә багышланган район марафоны”) үткәрү. “Күн туп”, “Алтын алка” Бөтенроссия ярышларының район, зона республика этапларын уздыру һәм аларда катнашу.

Россия һәм халыкара ярышларга район спортчыларын әзерләүне һәм катнашуын тәэмин итү. Татарстан Республикасы спорт мәктәпләре арасында укыту-тәрбия эшен иң яхшы куюга район конкурсын уздыру һәм республика смотр-конкурсында катнашу. Җәйге чорда "Спорт мәктәбе" МБУ, "БСББ(П)Ү" ӨББ МБУ укучылары өчен уку-тренировка сборлары оештыру һәм үткәрү.

Балык Бистәсе муниципаль районы "Спорт мәктәбе" МБУ, "Дельфин" спорт-сәламәтләндерү комплексы" МБУ, Балык Бистәсе муниципаль районы, спорт объектлары тренерлары арасында спорт-гаммәви һәм физкультура-сәламәтләндерү эшен иң яхшы куюга район конкурсы үткәрү турындагы нигезләмәләр эшләү,раслау һәм камилләштерү.

Физкультура-спорт юнәлешендәге белем бирү оешмалары (Спорт мәктәбе) эшенә спортчы паспортын кертү.

Тәҗрибә һәм методик материаллар тарату максатыннан район авыл җирлекләрендә, район предприятиеләрендә һәм оешмаларында физик культура һәм спортны үстерү буенча комплекслы тикшерүләр үткәрү.

"2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл яшьләре" муниципаль программасын тормышка ашыру.

**Таблица № 13. Спортны үстерү өлкәсендә чаралар**

| № | Чара | Үтәү сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Сәламәтлекне актив саклау һәм ныгыту, сәламәтлек культурасы дәрәҗәсен һәм потенциалын күтәрү, вакытыннан алда килүче үлем-китемне кисәтү. Уртача гомер озынлыгын арттыру һәм халык тормышының сыйфатын яхшырту | 2020-2030 еллар | ББМР БК, "Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек" МКУ (килешенү буенча) | - | - |

| № | Чара | Үтәү сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| 2 | Халыкның сәламәтлеген ныгыту буенча чараларда катнашуга мотивация тудыру, сәламәт яшәү рәвешенең индивидуаль һәм осталык күнекмәләрен үстерү. | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек” МКУ (килешенү буенча) | - | - |
| 3 | Районның спорт оешмаларын һәм учреждениеләрен гаммәви физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт занятиеләрен уздыруга һәм аларда катнашуга актив тарту | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек” МКУ (килешенү буенча) | - | - |
| 4 | Җирле үзидарә органнарына уен мәйданчыклары, хоккей тартмалары, инвентарь белән тәэмин итүдә булышу | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек” МКУ (килешенү буенча) | Агымдагы чыгымнар | МР бюджеты |
| 5 | Мәктәп һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларга физик тәрбия бирү сыйфатын күтәрү | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек” МКУ (килешенү буенча) | - | - |
| 6 | Эшләүче яшьләр, хезмәткәрләр һәм тулаем районыбыз яшьләре арасында спорт-сәламәтләндерү чараларын оештыру һәм уздыру. | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек” МКУ (килешенү буенча) | Агымдагы чыгымнар | МР бюджеты |
| 7 | Сәламәт яшәү рәвеше булдыру һәм социаль-негатив күренешләрне профилактикалау максатларында “Форпост” җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр берләшмәсе эшчәнлеген гамәлгә ашыру | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек” МКУ (килешенү буенча) | 2635,0 | ТР бюджеты |

| № | Чара | Үтәү сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| 8 | Физик культура һәм спорт өлкәсенә өстәмә ресурслар, иганәчелек чараларын җәлеп итү өчен шартлар тудыру. | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек” МКУ (килешенү буенча) | - | - |
| 9 | “Хезмәткә һәм оборонага әзер” (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәгән район гражданнарының өлешен арттыру | 2020-2030 еллар | ББМР БК, “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек” МКУ (килешенү буенча), “Мәгариф бүлеге” МКУ (килешенү буенча) | 1500,0 | ТР бюджеты |
| 10 | Универсаль спорт мәйданчыклары төзү һәм реконструкцияләү. | 2020-2021 еллар, 2030 елга кадәр фараз | ББМР БК, “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек” МКУ (килешенү буенча), “Дельфин” ССК” МБУ,”Спорт мәктәбе” (килешенү буенча) | 19221,1 | ТР бюджеты |
| 11 | Хоккей тартмалары төзү, спорт җиһазлары алу, спорт корылмаларын ел әйләнәсендә файдалану | 2020-2021 еллар | ББМР БК, “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек” МКУ (килешенү буенча), “Дельфин” ССК” МБУ,”Спорт мәктәбе” (килешенү буенча) | 3500,0 | ТР бюджеты |
| 12 | Ябык боз сарае төзү | 2021-2030 еллар | ББМР БК, “Яшьләр сәясәте, спорт | 280 000,0 | ТР бюджеты |

| № | Чара | Үтәү сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | һәм туризм буенча бүлек" МКУ (килешенү буенча) | | |
| 13 | Блоклы модульле чаңгы базасы төзү. | 2020 ел | ББМР БК, "Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек" МКУ (килешенү буенча) | 7681,4 | ТР бюджеты |
| 14 | Балык Бистәсе районы территориясендә "Өченче яшь" Спартакиадасы кысаларында халыкның урта һәм өлкән яшьтәге төркемнәре (ветераннар, олы яшьтәге кешеләр) арасында район, зона һәм республика физкультура-савыктыру, комплекслы, спорт чаралары уздыру һәм күрсәтелгән категориянең аларда катнашуы. "Сәламәтлек", "Авыл Яшьлере", "Спорт төрләре буенча муниципаль хезмәткәрләр спартакиадасы" кысаларында авыл районнары командалары арасында чемпионатлар, беренчелекләр, ачык турнирлар, комплекслы чаралар үткәрү. | 2020-2021 еллар | ББМР БК, "Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек" МКУ (килешенү буенча), "Дельфин" ССК" МБУ,"Спорт мәктәбе" (килешенү буенча) | 2262,5 | ТР бюджеты |
| 15 | Гомуми белем бирү оешмаларында спортның уен төрләрен үстерү, шул исәптән "КЭС-БАСКЕТТ" мәктәп баскетбол лигасы ярышларын үткәрү; "Мини-футбол - мәктәпкә!" гомумроссия | 2020-2021 еллар | ББМР БК, "Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек" МКУ (килешенү буенча), "Дельфин" ССК" | 2262,5 | ТР бюджеты |

| № | Чара | Үтәү сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| | проектын гамәлгә ашыру кысаларында мини-футбол буенча. “Президент бәйгеләре” ярышларында һәм фестивалендә катнашу, “Президент спорт уеннары” ярышлары. Популяр спорт-гаммәви чаралар (“Милләтләр кроссы”, “Россия чаңгы юлы”, “Бөек Ватан сугышында Җиңүнең еллыгын бәйрәм итүгә багышланган район марафоны”) үткәрү. “Күн туп”, “Алтын алка” Бөтенроссия ярышларының район, зона республика этапларын уздыру һәм аларда катнашу. | | МБУ,”Спорт мәктәбе” (килешенү буенча) | | |
| 16 | Россия һәм халыкара ярышларга район спортчыларын әзерләүне һәм катнашуын тәэмин итү. Татарстан Республикасы спорт мәктәпләре арасында укыту-тәрбия эшен иң яхшы куюга район конкурсын уздыру һәм республика смотр-конкурсында катнашу. Җәйге чорда “Спорт мәктәбе” МБУ, “БСББ(П)Ү” ӨББ МБУ укучылары өчен уку-тренировка сборлары оештыру һәм үткәрү | 2020-2021 еллар | ББМР БК, “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек” МКУ (килешенү буенча), “Дельфин” ССК” МБУ,”Спорт мәктәбе” (килешенү буенча) | - | - |

| № | Чара | Үтәү сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| 17 | Балык Бистәсе муниципаль районы “Спорт мәктәбе” МБУ, “Дельфин” спорт-сәламәтләндерү комплексы” МБУ, Балык Бистәсе муниципаль районы, спорт объектлары тренерлары арасында спорт-гаммәви һәм физкультура-сәламәтләндерү эшен иң яхшы куюга район конкурсы үткәрү турындагы нигезләмәләр эшләү, раслау һәм камилләштерү | 2020-2021 еллар | ББМР БК, “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек” МКУ (килешенү буенча), “Дельфин” ССК” МБУ,”Спорт мәктәбе” (килешенү буенча) | - | - |
| 18 | Физкультура-спорт юнәлешендәге белем бирү оешмалары (Спорт мәктәбе) эшенә спортчы паспортын кертү. | 2020-2021 еллар | ББМР БК, “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек” МКУ (килешенү буенча), “Дельфин” ССК” МБУ,”Спорт мәктәбе” (килешенү буенча) | - | - |
| 19 | Тәҗрибә һәм методик материаллар тарату максатыннан район авыл җирлекләрендә, район предприятиеләрендә һәм оешмаларында физик культура һәм спортны үстерү буенча күчмә комплекслы тикшерүләр үткәрү. | 2020-2021 еллар | ББМР БК, “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек” МКУ (килешенү буенча), “Дельфин” ССК” МБУ,”Спорт мәктәбе” | - | - |
| 20 | “2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл яшьләре” муниципаль программасын тормышка ашыру | 2020-2021 еллар | ББМР БК, “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлек” МКУ (килешенү буенча) | 3 371,5 | Җирле бюджет |

## 6.5. Халыкның мәшгульлеге һәм социаль ярдәм

Урбанизациянең җитди проблемаларының берсе аның стихияле характерда булуы, бу торак урыны һәм эш урыны булмаган авыл халкының шәһәргә килү проблемасының кискенләшүенә китерә. Бу процесста авыл халкы тарафыннан урта һөнәри һәм югары белем алу төп фактор булып тора һәм, кагыйдә буларак, төп тарту үзәге булып Казан шәһәре тора. Бу проблема башкаланың хезмәт базарына һәм аның инфраструктурасына басым артуга китерә, шулай ук Балык Бистәсе районының хезмәткә яраклы халкы өлешен сизелерлек киметә.

Шуны билгеләп үтү мөһим: урбанизация шәхси ярдәмче хуҗалыкларда авыл хуҗалыгы җитештерүен киметүгә алып бара.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: авыл торак пунктларыннан яшь кешеләрне тарту үзәге булып шулай ук Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы да тора. Балык Бистәсе штп. да хезмәт хакы дәрәҗәсе, ял итү хезмәтләре күләме авыл торак пунктларыннан яшьләр китүнең сизелерлек факторлары булып тора.

Тулаем алганда, ББМР хезмәт базары икътисади мөнәсәбәтләрнең катлаулы системасы булып тора. Хезмәт базарының төп элементлары – чынлыкта мәшгуль хезмәткәрләр, эшсезләр, “соры” хезмәт базарындагылар, шулай ук ҖҮО да мәшгульләр. 2019 ел башына хезмәт базарының торышы 14 нче таблицада күрсәтелгән.

**Таблица 14. ББМР хезмәт базарының 2019 ел башына торышы**

| Чараларның исеме | Күрсәткечләр (кеше) |
|---|---|
| **Мәшгульлек хезмәтенә барлыгы мөрәҗәгать итте:** | **1503** |
| яраклы эш эзләүдә булышуны сорап | 925 |
| хезмәт базарындагы хәл турында мәгълүмат алырга | 298 |
| һөнәри юнәлеш алу өчен | 640 |
| **Эш эзләүче буларак исәпкә куелды:** | **275** |
| шул исәптән мәшгуль булмаган гражданнар | 165 |
| **Барлыгы эшсез дип танылды** | **147** |
| **Эшсезлек буенча пособие билгеләнде** | **147** |
| **Барлыгы эшкә урнаштырылды:** | **170** |
| шулардан: | |

| | |
|---|---|
| мәшгуль булмаган гражданнар | 60 |
| балигъ булмаганнар | 110 |
| **Һөнәри яктан яңадан укытуга җибәрелгән гражданнар, барлыгы:** | **35** |
| ш.и. хатын-кызлар | 14 |
| 16-29 яшьләрдәге яшьләр | 11 |
| **Җәмәгать эшләренә җибәрелде** | **70** |
| **Эшкуарлык эшчәнлеге теркәлде** | **10** |
| **Күчеп кайтучылар (күченүчеләр)** | **0** |
| **Социаль адаптация (җайлашу) буенча хезмәтләр алдылар** | **27** |
| **2015 елның 1 гыйнварына исәптә торучы эшсезләр саны** | **49** |
| **Җенесе буенча:** | |
| хатын-кызлар | 21 |
| **Яше буенча:** | |
| 16-29 яшьләрдәге яшьләр | 5 |
| пенсия алды яшендәгеләр | 9 |
| **Мәшгуль булмау сәбәпләре буенча:** | |
| үз теләкләре белән эштән киткәннәр | 15 |
| азат ителгәннәр | 16 |
| эшеннән озак вакытка бүленеп торучылар (тәнәфестәге) | 8 |
| хәрби хезмәттән азат ителгәннәр | - |
| ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар | - |
| уку йортларын тәмамлаучылар | 1 |
| **Белеме буенча:** | |
| югары һөнәри | 14 |
| урта һөнәри | 23 |
| урта | 12 |
| **01.01.2016 на эшсезлек дәрәҗәсе (%)** | **0,39** |
| **Эшсезлекнең уртача дәвамлылыгы (айларда)** | **5,11** |
| **Пособиенең уртача күләме (сум)** | **3510** |
| **Предприятиеләрнең буш эш урыннарын алмаштыру өчен хезмәткәрләргә ихтыяҗы, барлыгы** | **514** |
| алар арасыннан: эшче һөнәрләргә | 295 |

Эшсезлек буенча исәптә торучы югары белемле гражданнар саны 14 кешене тәшкил итте, алар нигездә түбәндәге һөнәрләргә ия: зооинженер, икътисадчы, бухгалтер, укытучы, инженер, педагог-психолог, юрист, технолог.

Эшсезлек буенча исәптә торучы урта һөнәри белемле гражданнар саны-23 кеше, аларның күбесе түбәндәге квалификацияләргә ия: пешекче, юрист, икътисадчы, шофер, бухгалтер, электр белән эретеп ябыштыручы, тракторчы һ. б.

Предприятие һәм оешма хезмәткәрләрен эштән азат итү хезмәткәр инициативасы буенча гына түгел, ә түбәндәге сәбәпләр аркасында да башкарыла: оптимальләштерү, предприятиеләрне бетерү, нәтиҗәдә хезмәткәрләр саны яки штат кыскару котылгысыз.

Кеше капиталын һәм хезмәт базары балансын үстерү өлкәсендә **проблемалар** сыйфатында түбәндәгеләрне тәгъбирләргә мөмкин:

- урта һөнәри һәм югары һөнәри белеме булган хезмәткә яраклы яшьтәге кешеләр арасында эшсезлекнең югары дәрәҗәсе;
- хезмәт хакы ББМР буенча уртача хезмәт хакыннан югарырак булган кирәкле сандагы буш эш урыннары булмау;
- түбән хезмәт хакы;
- соры базарда эшләүчеләр саны арту;
-түбән пенсия.

**Тәгъбирләнгән проблемаларны хәл итү өчен чаралар:**

Урта һөнәри һәм югары һөнәри белемле эшсез гражданнарның мәшгуль булмау сәбәпләренә анализ ясау. Халыкны эшкә урнаштыру өчен инвестицион тәкъдимнәр әзерләү.

Хезмәткәрләрнең хезмәт хакы артканда хуҗалык субъектлары өчен муниципаль преференцияләр бирү буенча тәкъдимнәр әзерләү.

Лидерлык сыйфатларын үстерү максатында урта һәм югары һөнәри белемгә ия кешеләр белән тренинглар үткәрү.

Авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре заказы буенча шәхси ярдәмче хуҗалыкларда кош, дуңгыз һәм мөгезле эре терлекләр үстерү буенча проектлар эшләү һәм тормышка ашыру.

Хуҗалык итүнең  кече формаларына “симметрик финанс ярдәме” турында икътисади зонаның иҗтимагый инвестицион советына (ИЗИИС) тәкъдимнәр кертү өчен шундый ук эре хуҗалыкларга тәкъдим итү (җитештерелгән продукция күләмнәре критерийлары буенча).

ББМР ның урта һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларга ихтыяҗына анализ үткәрү һәм, кирәк булганда, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына әзерләү юнәлешләрен үзгәртүне тәкъдим итәргә.

Икътисади зонаның башка муниципаль районнары белгечләренә укыту, күнекмәләр һәм тәҗрибә бирү өчен ББМР да АПК белгечләрен әзерләү буенча Координация-ресурс үзәге булдыру.

АПК өлкәсендә эшче һөнәрләр буенча ел саен зона смотр-конкурсын үткәрү.

Авыл җирендә белгечләр өчен сатып алу вакыты кичектерелгән арендалы торак төзү.

**Таблица № 15. Халыкны эш белән тәэмин итүне үстерү һәм социаль ярдәм өлкәсендәге чаралар**

| № | Чара | Үтәү сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | ББМР ның урта һөнәри һәм югары һөнәри белемле эшсез гражданнарының мәшгуль булмау сәбәпләренә анализ ясау. Халыкны эшкә урнаштыру өчен инвестицион тәкъдимнәр әзерләү | 2020-2030 еллар | ББМР БК, Мәшгульлек үзәкләре (килешенү буенча) | - | - |

| № | Чара | Үтәү сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| 2 | Хезмәткәрләрнең хезмәт хакы артканда хуҗалык субъектлары өчен муниципаль преференцияләр бирү буенча тәкъдимнәр әзерләү | 2020-2030 еллар | ББМР БК | - | - |
| 3 | Лидерлык сыйфатларын үстерү максатында урта һәм югары һөнәри белемгә ия кешеләр белән тренинглар үткәрү | 2020-2030 еллар | ББМР БК | - | - |
| 4 | ББМР ның урта һөнәри һәм югары һөнәри белемле эшсез гражданнарының мәшгуль булмау сәбәпләренә анализ ясау. Халыкны эшкә урнаштыру өчен инвестицион тәкъдимнәр әзерләү | 2020-2021 еллар | ББМР БК, Мәшгульлек үзәкләре (килешенү буенча) | - | - |
| 5 | ББМР ның урта һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларга ихтыяҗына анализ үткәрү һәм, кирәк булганда, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына әзерләү юнәлешләрен үзгәртүне тәкъдим итәргә. | 2020-2021 еллар | ББМР БК | - | - |

| № | Чара | Үтәү сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Авыл җирендә белгечләр өчен сатып алу вакыты кичектерелгән арендалы торак төзү | 2020-2021 еллар | ББМР БК | - | ТР бюджеты |

Әлеге чараларны тормышка ашыру, фаразлар буенча, хезмәткә яраклы халык санын һәм эшлекле активлыкны арттыруга китерергә мөмкин.

**Социаль ярдәм**

**Таблица № 16. Балык Бистәсе районында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районындагы “Доверие-Ышаныч” ХСХККҮ” ДАСХКУ буенча проблемалар һәм аларны 2030 елга кадәр хәл итү юллары**

| № | Проблема | Аларны хәл итү юллары | Көтелгән нәтиҗәләр | Тормышка ашыру елы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр | Гаиләнең имин булмавын иртә ачыклау һәм социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрне һәм балаларны исәпкә кую буенча ведомствоара хезмәттәшлек | Күзәтүчесез балаларның ТР буенча тәгаенләнгән кыйммәтеннән артык булмаган тоткан урынына ирешү | 2030 елга кадәр | ББМР БК, “Доверие-Ышаныч” ХСХККҮ” ДАСХКУ (килешенү буенча), Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге (килешенү буенча), җирле үзидарә органнары |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2 | Коммерциячел булмаган оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү | Грант акчаларын җәлеп итү буенча конкурсларда катнашу | Мөһим социаль функцияләрне үтәү эшчәнлеген гамәлгә ашыру | 2030 елга кадәр | ББМР БК, КБО (килешенү буенча) |
| 3 | Социаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты һәм һәркем өчен мөмкин булуы | Учреждение хезмәткәрләренең квалификация дәрәҗәсен күтәрү | Өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның актив тормыш позициясен саклап калу | 2021 елга кадәр. | ББМР БК, "Доверие-Ышаныч" ХСХККҮ" ДАСХКУ (килешенү буенча) |
| 4 | Социаль хезмәтләр базарын үстерү | Максатчан программалар эшләү | Өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның актив тормыш позициясен саклап калу | 2021 елга кадәр | ББМР БК |

## 7. Территорияне үстерү

Территорияләрне үстерүнең төп максаты: торак пунктларны төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү, социаль әһәмияткә ия объектлар төзү, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын норматив хәлгә китерү.

### 7.1. Торак төзелеше һәм территорияләрне төзекләндерү

Балык Бистәсе муниципаль районының төзелеш һәм инфраструктура үсешенең төп **максатлары:**

- халыкның яшәве өчен уңай шартлар тәэмин итү;
- һәркем өчен мөмкин булган торак базары булдыру;
- районның инфраструктурасын үстерү.

**Бурычлар:**

- “Россия гражданнарына – һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак” милли проектын, ипотека торак кредитлау программасын, күчемсез мөлкәт базарын үстерү һәм торак урыннарына мохтаҗ гражданнарга карата социаль наем шартнамәләрен тормышка ашыру юлы белән һәркем өчен мөмкин булган торак һәм халыкка уңайлы яшәү шартлары тәэмин итү;

- район территориясендә төзелешнең эшләнгән генераль планы нигезендә эксплуатация чыгымнарын киметүгә ярдәм итә торган яңа технологияләр кулланып торак һәм инженерлык коммуникацияләре төзү;

- төзелеш процессын оештыру дәрәҗәсен һәм төзелеш эшләренең сыйфатын күтәрү;

- төзелеш тармагын үстерүгә хосусый капитал җәлеп итү өчен уңай шартлар тудыру.

2010-2018 еллар чорында файдалануга тапшырылган гомуми торак күләме 103,674 мең кв. метр тәшкил итте.

2018 елда район халкы индивидуаль торак йортлар төзегәндә 300 млн. сумга якын инвестицияләр керткән. 2018 елда 13,5 мең кв. метр торак төзелгән һәм файдалануга тапшырылган: бу – 125 индивидуаль торак йорт. 2019 елның 1 гыйнварына Балык Бистәсе районында торак фонды мәйданы 798,2 мең кв.м тәшкил итте.

Шулай итеп, бездә 1 кешегә 31,6 кв. м торак туры килә. Актив төзелеш Балык Бистәсе штп.ның “Төньяк” бистәсендә алып барыла, 185 торак йорт төзелде, электр үткәрелде, су, газ белән тәэмин итү эшләнде.

Узган ел район 21 республика программасында катнашты, бу районның йөзен шактый дәрәҗәдә үзгәртте.

Соңгы елларда 466 Бөек Ватан сугышы ветераны уңайлы торак алды. “2020 елга кадәр авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” федераль максатчан программасы зур ярдәм күрсәтә, аның кысаларында 2018 елда 35 гаилә торак шартларын яхшыртуга гомуми күләме 31 767 мең сумлык субсидия алды.

Югарыда күрсәтелгән программаларны уңышлы гамәлгә ашыру, шулай ук район халкы тарафыннан индивидуаль торак йортлар төзү 2020 елга 27,0 мең кв. м торак төзергә һәм бер кешегә 33,5 кв. м исәбеннән гомуми торак мәйданы белән тәэмин ителеш күрсәткеченә ирешергә мөмкинлек бирәчәк, ә 2030 елга – 35,5 кв. м.

**Таблица № 17. Бер кешегә исәпләгәндә гомуми торак мәйданы белән тәэмин ителеш**

| Күрсәткечләр | Еллар | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2024 | 2025 | 2030 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Халыкның уртача еллык саны, мең кеше | База сценарие буенча | 25,61 | 25,25 | 24,89 | 24,53 | 24,17 | 24,34 | 24,46 | 25,68 |
| Бер кешегә исәпләгәндә торакның гомуми мәйданы белән тәэмин ителеш, кв. метр | База сценарие буенча | 30,9 | 31,6 | 32,5 | 33,5 | 34,5 | 34,7 | 35,0 | 35,5 |

Күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү турындагы Федераль законны гамәлгә ашыру кысаларында су белән тәэмин итү, канализация һәм җылыту системаларын реконструкцияләү һәм ремонтлау, күмәк һәм индивидуаль исәпкә алу приборлары урнаштыру буенча зур эш башкарылды. Бу юнәлештә эш 2020 елга кадәр дәвам итәчәк һәм капиталь кертемнәр күләме 23,6 млн.сум тәшкил итәчәк.

Масловка авылында сәламәтлек саклау объектларын модернизацияләү кысаларында модульле фельдшер-акушерлык пункты төзелде, “Ягодка” балалар бакчасына капиталь ремонт ясалды, универсаль спорт мәйданчыгы файдалануга тапшырылды.

Күки авылында 100 урынга исәпләнгән күпфункцияле үзәк ачылу безнең өчен истәлекле, мөһим вакыйга булды.

“Иҗтимагый киңлекләрне үстерү” программасы буенча Ленин урамы буенча 11 млн.сумга төзелешнең 1 этабы, шулай ук Совет урамы буенча Мәчет скверын төзүнең 1 этабы тәмамланды.

**Хәл итү юллары:**

ББМР ның капиталь төзелеш, ремонт һәм модернизацияләү буенча республика программаларында катнашуы;

юл төзелеше программаларында катнашу;

ББМР ның авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару генераль планнарын һәм кагыйдәләрен эшләү һәм раслау;

Котлы Бөкәшнең “Дуслык” МБМББУ балалар бакчасында капиталь ремонт;

“Агротехника техникумы” ДАҺБУ дә капиталь ремонт;

Балык Бистәсе штп.да блоклы-модульле чаңгы базасы төзү;

Олы Елга авылында блоклы-модульле кибет төзү;

Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселокта 90 кешелек Балалар сәламәтләндерү лагере төзү;

Балык Бистәсе штп.да Яшьләр үзәге төзү;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районындагы “Доверие-Ышаныч” ХСХККҮ” ДАСХКУ бинасына капиталь ремонт;

Биектау авылында 50 урынлык балалар бакчасы төзү;

Тәберде Чаллысында ФАП төзү;

“Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе” ДАССУ поликлиникасы төзелешен төгәлләү;

Биектау авылында күпфункцияле үзәк төзү;

Шумбут авылында спорт мәйданчыгы төзү;

Күпфатирлы йортларга капиталь ремонт;

Авыл советлары биналарын капиталь ремонтлау;

Котлы Бөкәш авылы Мәдәният йортына капиталь ремонт;

Балык Бистәсе штп.да Ленин урамының үзәк өлешен төзекләндерү (3 чират);

Торак төзелешен үстерү һәм территорияләрне төзекләндерү өлкәсендәге чаралар;

Һәркем өчен мөмкин булган торак базары булдыру һәм гражданнарның уңайлы яшәү шартларын тәэмин итү;

Төрле типтагы аз катлы төзелешләрне киң куллану (утар, коттедж, югары ныклыктагы аз катлы блоклы төзелеш);

Гамәлдәге торак фондын исәпкә алуны корректировкалау (төзәтмәләр кертү), аның составында еш кына халык тарафыннан күптән ташланган йортларның мәйданы кала, ләкин балансстан сызылмаган, ә бу торак белән тәэмин ителешнең чынбарлыктагы күрсәткечләрен, шулай ук яңа төзелешнең исәп-хисап күрсәткечләрен боза;

Демографик хәлне яхшырту, нәтиҗәле миграция сәясәтен гамәлгә ашыру һәм торак проблемасын хәл итү хисабына муниципаль берәмлекләрнең тотрыклы үсеше өчен шартлар тудыру;

Салым ташламаларын бирү хисабына инвесторларга һәм төзүчеләргә ярдәм итү;

Төзелеш индустриясе һәм төзелеш материаллары сәнәгатен үстерү;

Торак төзелешенең конкурентлы базарында торак тәкъдимен арттыру өчен коммуналь инфраструктураны узып китәрлек итеп (алгарышлы) үстерүне тәэмин итү;

Төзелеш өчен әзерләнгән җир кишәрлекләре базары булдыру.

**Таблица № 18. Торак төзелешен үстерү һәм территорияләрне төзекләндерү өлкәсендә чаралар**

| № | Чара | Үтәү сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | ББМР ның капиталь төзелеш, ремонт һәм модернизацияләү буенча республика программаларында катнашуы | 2020-2030 еллар | ББМР БК | - | ТР бюджеты |
| 2 | Муниципаль юл фонды акчалары хисабына юл эшләрен башкару | 2020-2030 еллар | ББМР БК | - | Җирле бюджет |
| 3 | ББМР авыл җирлекләренең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару генераль планнарын һәм кагыйдәләрен эшләү һәм раслау | 2020-2021 еллар | ББМР БК, җирле үзидарә органнары | - | Җирле бюджет, ТР бюджеты |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Котлы Бөкәшнең “Дуслык” МБМББУ балалар бакчасында капиталь ремонт | 2020 г. | ББМР БК | 8 321,58 | ТР бюджеты |
| 5 | “Күгәрчен УГББМ” МБМУ нә ремонт (2 этап) | 2020 ел | ББМР БК | 8 321,58 | ТР бюджеты |
| 6 | “Агротехника техникумы” ДАҺБУ дә капиталь ремонт | 2020 ел | ББМР БК | 80 000,00 | ТР бюджеты |
| 7 | Балык Бистәсе штп.да блоклы-модульле чаңгы базасы төзү | 2020 ел | ББМР БК | 100 000,00 | ТР бюджеты |
| 8 | Олы Елга авылында блоклы-модульле кибет төзү | 2020 ел | ББМР БК | 3 000,00 | ТР бюджеты |
| 9 | Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселокта 90 урынга Балалар сәламәтләндерү лагере төзү | 2020 ел | ББМР БК | 40 000,00 | ТР бюджеты |
| 10 | Балык Бистәсе штп.да Яшьләр үзәге төзү | 2020 ел | ББМР БК | | ТР бюджеты |
| 11 | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районындагы “Доверие-Ышаныч” ХСХККҮ” ДАСХКУ бинасына капиталь ремонт | 2020 ел | ББМР БК | 2 000,00 | ТР бюджеты |
| 12 | Биектау авылында 50 урынга балалар бакчасы төзү | 2020 ел | ББМР БК | 84 000,00 | ТР бюджеты |
| 13 | Тәберде Чаллысы авылында ФАП төзү | 2020 ел | ББМР БК, “Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе” ДАССУ (килешенү буенча) | 3 772,00 | ТР бюджеты |
| 14 | Шумбут авылында спорт мәйданчыгы төзү | 2020 ел | ББМР БК | 5 000,00 | ТР бюджеты |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 15 | Биектау авылында күпфункцияле үзәк төзү | 2020 ел | ББМР БК | 21 000,00 | ТР бюджеты |
| 16 | Авыл җирлекләре Советлары биналарын капиталь ремонтлау | 2020 ел | ББМР БК | 3 000,00 | ТР бюджеты |
| 17 | Күпфатирлы йортларга капиталь ремонт | 2020 ел | ББМР БК | 6 348,48 | ТР бюджеты, җирле бюджет |
| 18 | Котлы Бөкәш авылы Мәдәният йортына капиталь ремонт | 2020 ел | ББМР БК | 3 000,00 | ТР бюджеты |
| 19 | Балык Бистәсе штп.да Ленин урамының үзәк өлешен төзекләндерү (3 чират) | 2020 ел | ББМР БК | 14 000,00 | ТР бюджеты |
| 20 | “Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе” ДАССУ поликлиникасы төзелешен тәгәлләү | 2020 ел | ББМР БК, “Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе” ДАССУ (килешенү буенча) | - | ТР бюджеты |
| 21 | Балык Бистәсе районы торак пунктларында урамнарны яктырту челтәрләрен модернизацияләү | 2020 ел | ББМР БК, җирле үзидарә органнары | Агымдагы финанслау | ТР бюджеты |

### 7.2. Торак-коммуналь хуҗалыгы

Торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру халыкка хезмәт күрсәтү сыйфатын күтәрүне, аның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауны, шулай ук тармакның тулаем тотрыклы һәм нәтиҗәле эшләвен тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Торак-коммуналь хуҗалыкны үстерүнең максаты – районның торак-коммуналь комплексы эшләвенең югары ышанычлылык һәм тотрыклылыгы дәрәҗәсенә ирешү, күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту, районда ягулык-энергетика ресурсларын куллануның нәтиҗәлелеген арттыру.

Бурычлар:

1. Күрсәтелгән торак-коммуналь хезмәтләр өчен халык акчаларын һәм бюджет чыганакларын куллануның нәтиҗәлелеген арттыру.

2. Торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә чыгымнарны рациональләштерү һәм киметү.

3. Күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты өчен ТКИ җитештерүчеләренең кулланучылар алдында җаваплылыгы системасын камилләштерү.

4. Яңа энергонәтиҗәле технологияләр һәм җиһазлар кертеп җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм су бүлү муниципаль системасының искергән технологик җиһазларын модернизацияләү һәм алмаштыру.

5. Муниципаль торак контроле системасының нәтиҗәлелеге системасын кертү.

Балык Бистәсе муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалыгын "Теплоэнергосервис" МУП оешмасы тәкъдим итә.

"Теплоэнергосервис" МУП халыкка һәм бюджет учреждениеләренә җылылык энергиясен җибәрә. Аларның балансында 15 котельный бар, алар газда эшли.

## Җылылык хуҗалыгының торышы һәм проблемалары

Инженерлык инфраструктурасы һәм җиһазларының шактый күләме мораль һәм физик яктан искергән, энергияне күп сарыф итәләр, аз нәтиҗәлеләр, кулланганда һәм ремонтлауда катлаулы. Гамәлдәге котельныйларда заманча таләпләргә туры килми торган казаннар урнаштырылган, 163,11 кг шартлы ягулыкны чагыштырма сарыф иткәндә КПД түбән (80-84%), яну куркынычсызлыгы автоматикасы Ростехнадзор органнары таләпләренә туры килми, котельныйларда суны казанга кадәрге эшкәртү 80% тәшкил итә.

Нигездә, җылылык челтәрләренең гамәлдәге өлеше икеторбалы башкаруда һәм каналлы вариантта (50%) салынган, калган өлеше заманча технология буенча – полиэтилен тышчада пенополиуретан изоляциясендә каналсыз вариантта салынган.

Территориаль котельныйлар бер-берсеннән шактый ерак урнашкан, бу аларны җылылык челтәрләре төземичә бердәм җылылык челтәренә берләштерергә мөмкинлек бирми.

Котельныйларны модернизацияләү буенча чаралар:

-“Күгәрчен УГББМ” МБМУ котельныенда казанны алмаштыру, шулай ук ИГК тибындагы эффектив яну җайланмалары һәм казаннарның 93% КПД белән эшен тәэмин итүче куркынычсызлык автоматикасы белән ярдәмче җиһазны алыштыру.

- реагентларны дозировкалауның автоматлаштырылган җайланмаларын куллану чыгымнарны шактый дәрәҗәдә киметергә мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта суның коррозион активлыгы кими, элек булган утырмалар акрынлап юкка чыгарыла, җиһазларны эксплуатацияләү вакыты һәм ремонтара чор арта.

-автоматиканың һәм газ горелкаларының яңа төрләрен, химводоподготовканың автоматлаштырылган җайланмаларын, ешлык көйләүле электроприводы белән насос станцияләрен куллану котельныйларны тулысынча автоматлаштыру һәм диспетчерлаштыру мөмкинлеген бирә, бу исә эксплуатация чыгымнарын, үзкыйммәтне, тиңдәшле рәвештә җибәрелә торган җылылык энергиясенә тарифларны киметергә мөмкинлек бирәчәк.

2030 елга кадәрге чорга җылылык куәте кытлыгы фаразланмый.

Җылылык куәте кытлыгы булган зоналардан җылылык йөкләнешен җылылык куәте артык булган зоналарга башкача (яңадан) бүлүне тәэмин итүче җылылык челтәрләрен реконструкцияләү һәм төзү күздә тотылмый.

Балык Бистәсе штп.ның гамәлдәге чыганакларының урнашкан суммар куәте һәм аларның җылылык белән нәтиҗәле тәэмин итү радиусы барлык җылылык йөкләнешләрен каплау өчен җитәрлек.

Балык Бистәсе штп.да җылылык йөкләнешенең перспективадагы үсешен тәэмин итү өчен яңа төзелә торган объектларны проектланучы автоном блоклы-модульле котельныйларга тоташтыру планлаштырыла.

**Су белән тәэмин итү** Балык Бистәсе штп.да җир асты чыганакларыннан гамәлгә ашырыла.

Хәзерге вакытта предприятие балансында туплану сыешлыклары һәркайсының 200 м3 булган алты су алу җайланмасы, туплану сыешлыклары 16 шар м3 булган 9 артезиан скважинасы (2003-2018 елларда төзелгән) бар.

Барлык скважиналарда да җитештерүчәнлеге тәүлеккә 1 230 м3 булган ЭЦВ маркалы насослар урнаштырылган.

Суүткәргеч челтәрләрнең озынлыгы 69 км, шуның 23% ы тирәсе алыштыруга мохтаҗ корыч торбалар (15,9 км), ә калганнары полимер материалдан. Суүткәргеч челтәрләрендә янгын сүндерүне тәэмин итү өчен 25 янгынга каршы гидрант, ә шәхси секторда су алу өчен 227 кое урнаштырылган.

Су белән тәэмин итүдәге проблемалар:

- эчәргә яраклы су санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә туры килми, катылык тозлары буенча 3,1 тапкыр артып китә;
- су чистарту юк;
- су белән тәэмин итү системасы канәгатьләнерлек хәлдә. Ел саен тузу арта, ул аварияләр саны артуга булышлык итә, су алу җайланмаларының бер өлешенең төзекләндерелгән санитар саклау зоналары юк.

Поселокта яшәүчеләрне эчәргә яраклы су белән тәэмин итү максатларында түбәндәге чараларны үткәрү планлаштырыла:

- барлык суүткәргеч скважиналарга Лоцман тибындагы саклагыч электр җиһазын урнаштыру;
- Балык Бистәсе штп.да су үткәрү челтәрләрен реконструкцияләү;
- гамәлдәге су җыю (алу) корылмаларын реконструкцияләү һәм киңәйтү;
- яңа сулыклар төзү;
- су куллануны исәпкә алу төеннәрен (узелларын) кертү;
- насос җиһазларын экономиялерәк җиһазларга алыштыру;
- ешлыгы көйләнүле электропривод кертү, насосларны салмак кына җибәрү җайланмасы;

- сулыкларны божралау, басым регуляторлары урнаштыру, челтәрләрнең гидравлик режимын оптимальләштерү.

Шуның белән бергә, район торак пунктларында су мәсьәләсе бүген бик кискен тора. Су белән тәэмин итү челтәрләренең күбесе узган гасырның 70 нче елларында төзелгән һәм реконструкция таләп итә.

**Агып җыела торган (агынты) суларны чистарту** Балык Бистәсе штп. да санитар-экологик торышны яхшыртуга юнәлдерелгән чара булып тора.

Канализациянең чистарту корылмалары эшенең нәтиҗәлелегенә, агынты суларны чистарту дәрәҗәсенә әйләнә-тирә мохитнең торышы да, халыкның сәламәтлеге дә бәйле бит.

2019 елда гамәлдәге БЧК ны (биологик чистарту корылмасын) Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогында модернизацияләү алып барыла.

**Агынтыларны күчерү** 9,2 км озынлыктагы канализация челтәрләре буенча канализация насос станциясе (КНС) аша башкарыла.

Канализация хуҗалыгын модернизацияләүнең төп юнәлешләре:

- агынты суларны йөртүгә, чистартуга электр энергиясе чыгымын киметү ;
- пычрану күрсәткечләрен киметү, агынтыларны чистарту сыйфатын, санитар-эпидемиологик хәлне яхшырту;
- төп фондларның тузуын киметү, канализациянең ышанычлылыгын арттыру.

**Территорияләрне санитар чистарту**

Торак пунктлар өчен нормаль санитар-гигиеник шартлар, шул исәптән санитар төзекләндерүнең югары дәрәҗәсен булдыру зур әһәмияткә ия.

Балык Бистәсе штп., Анатыш, Полянка, Тройцкий Урай, Масловка, Олы Елга, Балтач, Ямаш авылы территорияләрендә планлы-даими чистарту тормышка ашырыла. Калдыкларны җыю һәм алып китү расланган графиклар һәм маршрутлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Балык Бистәсе муниципаль районында Балык Бистәсе штп. на якын урнашкан каты көнкүреш калдыклары (ККК – ТБО) полигоны бар. Полигон 2002 елда файдалануга тапшырылган һәм 14 ел инде кулланылышта. Полигонның мәйданы 4,6 га, сыйдырышлылыгы 62,5 мең куб. м ны тәшкил итә.

Халыктан икенчел чимал җыюның стационар яки күчмә кабул итү пунктларын оештыру, каты көнкүреш калдыклары полигонында махсус чүп-чарны сортларга аеру цехларын җиһазлау юлы белән каты көнкүреш калдыкларын аерым җыюны

Каты көнкүреш калдыкларын алдан сортларга аеру һәм аннан соңгы эшкәртүне оештырганда, полигоннарда көнкүреш калдыкларын күмү күләмен 40% ка һәм аннан да күбрәккә киметергә, гамәлдәге полигоннарны файдалану вакытын 2-2, 5 мәртәбәгә арттырырга мөмкин.

**Калдыклар белән эш итү системасын үстерү чаралары**

Балык Бистәсе районы территориясенең каты көнкүреш калдыклары белән пычрануын киметү максатларында тәкъдим ителә:

- Балык Бистәсе штп. полигонында каты көнкүреш калдыкларын сортларга аеру комплексы төзү;
- каты көнкүреш калдыкларының җирлекара полигоннарын проектлау, төзү һәм җиһазлау;
- каты көнкүреш калдыкларын махсус җиһазландырылган контейнер мәйданчыкларында урнашкан контейнерларга җыю;
- урамнарны, мәйданнарны, скверларны һәм башка җәмәгать урыннарының калдыклар белән чүпләнүен булдырмас өчен сыйдырышлыгы 30 литрдан да ким булмаган урналар куярга;
- җирле үзидарә Советы каты көнкүреш калдыкларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешма белән берлектә махсус автотранспорт хәрәкәте графигын һәм территориядән көнкүреш калдыкларын чыгару графигын төзи һәм раслый.
- гаеплеләрне административ җаваплылыкка тартып юридик һәм физик затлар тарафыннан хокук бозуларны ачыклау буенча әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә эшне көчәйтергә.

## Таблица № 19. Районның экологик иминлеген тәэмин итү һәм торак-коммуналь өлкәсен яхшырту буенча чаралар

| № | Чара | Үтәү сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре, мең сум | Чыганак |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | "Күгәрчен УГББМ" МБМУ котельныенда казанны алмаштыру | 2020 ел | ББМР БК, Газлаштыру фонды | 0,9 | ТР бюджеты |
| 2 | Яңа Арыш авылында су белән тәэмин итү челтәре төзү (4 этап) | 2020 ел | ББМР БК, Газлаштыру фонды | 15 000 | ТР бюджеты |
| 3 | Рус Әшнәге авылында су белән тәэмин итү челтәре төзү | 2020-2022 еллар | ББМР БК, Газлаштыру фонды | 14 543,00 | ТР бюджеты |
